**Ирек Сабиров**

# МАНЗАРА

*Шигырьләр*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2004

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-5
С 12

**Сабиров Ирек**

Манзара: Шигырьләр. –Казан: Татар. кит. Нәшр., 2004. – 111 бит.

Тумышы белән Биектау районының Мәмдәл авылыннан булган Ирек Сабиров бүген чиләбе өлкәсенең Еманжелинск шәһәрендә яши, шәһәр башлыгының сәнгать башлыгы урынбасары булып эшли.

Әлеге китапка авторның туган жиргә, ата-анага булган кайнар хисләрен чагылдырган, мәхәббәткә дан җырлаган шигырьләре тупланды.

ISBN 5–298–01404–6
© Татарстан китап нәшрияты, 2004

## МӘДХИЯ

Яз җылысы бирдең, рәхмәт Сиңа!
Өмет бөркеп янды күкләрең;
Тәүге яшен булып балкыдың да
Уңыш вәгъдә итеп күкрәдең.

Рәхмәт Сиңа, яз ләззәте бирдең.
Әмма, Раббым, үзең беләсең:
Рәхмәт укып көттем мин җиһанның
Һәр суыгын, һәрбер чилләсен,
Һәр шатлыгын. Ә кайгылар килсә,
Күрми икән мине, димәдем;
Синнән генә көттем ярлыкауны,
Бүтәннәргә башым имәдем.

...Кояшкаең байый. Тик мин беләм
Таңнарыңның якты буласын.
Киләчәгем мәңге Синең белән,
Рәхмәт Сиңа, рәхмәт, Илаһым!

## БЕЗ

Без – имансыз булып үскән
Чал сакаллы сабыйлар.
Безнең имгәк җаннар өчен
Тәңре булды – фанилар.

Уйдырмалар чыгаруда
Булды безнең ireклек.
Шук җырларны – азгынлык, дип,
Мул тормышны – явызлык, дип,
Кырыслыкка күнектек.

Җырлар тыеп, җаннар кыеп
Урнаштырдык тынычлык.
Мал белән дә, рух белән дә
Баемаска тырыштык.

Бүген исә, комсызланып,
Калдык малны бүләләр
Кичә изге булып йөргән
Шома йөзле түрәләр.

Ачылган йөз, чишелгән эш –
Йөрәкләрдә кара ук:
Ышанырлык киләчәк юк,
Инанырлык җаннар юк.

Инде татлы телебездә
Доганың иң затлысы;
Әмма безне Ходаебыз
Ташлагандыр, ахрысы...

## ҖӘЙЛӘР АША, КЫШЛАР АША...

Җәйләр аша, кышлар аша,
Көннәр, төннәр аркылы,
Бер елмайтып, бер елатып,
Ага тормыш ташкыны.

Дулкыннарда сикертә дә,
Упкынга илтеп кертә,
Бер кычкырып җырлыйм, дисәм,
Ташка бәреп үкертә.

Йә чумабыз, йә йөзәбез,
Йә сайлыкта ятабыз;
Юлдашларны йә назлыйбыз,
Йә мылтыктан атабыз.

Йә зәңгәр су, йә болганыч,
Бер шатлык, бер үкенү;
Йә Ходайга саф гыйбадәт,
Йә кабахәт сүгенү.

Бер куаныч бар, ичмаса:
Ага ташкын кыйблага.
Анда – кояшым. Күзләрем,
Ымсынып, шуңа бага.

## ШАТЛАНЫРГА ТЕЛӘҮ

Таң уятты. Кояшлы март.
И матурлык, и ләззәт!
Эреп юкка чыккан кебек
Ызгыш, талаш, сәясәт.

Якты йөзле карлы кырлар...
Әй иркенлек, әй рәхәт!
Әллә исән калган микән
Ботарланган мәмләкәт?

Яз килгән, яз!.. Шатлыгымнан
Йөгерәсе, көләсе...
Кем әйткән ул үлгән, диеп,
Халыклар гаиләсе?

Тәрәзәмдә – көләч кояш,
Өемдә мул табын бар;
Әллә төштә күренгәнме
Канга баткан авыллар?

Шундый якты дөньябызда
Ызгыш-сугыш мөмкинме?
Бәхет теләп яраткан бит
Хак Тәгалә бу көнне...

## ӘТИЕМ КАБЕРЕ ЯНЫНДА

1

Килгән саен көям, карап

Зират миләшләренә.
Синсез яшәп, бик сусадым
Синең киңәшләреңә.
Монда тынлык. Тик миләшләр
Елап шыңшый зар көен;
Күрешүләр мөмкин түгел,
Әмма нишлим, этием, –
Рухым сиңа тартыла шул,
Бүген тагын түзмәдем:
Калгандыр, дим, йөрәгеңдә
Әйтелмәгән сүзләрең.
Кабат килеп, көннәремне
Синең янда уздырам;
Сиңа уйларымны сөйләп,
Сине тыңлап утырам.

2

Без үскәндә вәгазь кылып тордың,
Сүз җебеңне башлап ерактан:
«Татармы син, русмы – һәммәбезне
Хак Тәгалә тигез яраткан.
Тигезлеккә өнди илебездә
Күрсәтмәләр, закон-кануннар...»
...Аһ, этием, үзем сиздем: бездә
Язылмаган нәҗес канун бар.
Тугры булдым сиңа, шуңа микән
Һәр бәндәне җирдә дус иттем;
Ярсып сөйдем Рәсәй кырларында
Һәр үләннең, гөлнең хуш исен.
Үземне дә үз иттеләр бугай, –
Дусларга бай якын-тирәләр;
«Басурман», – дип, күзгә туры карап
Сүкмәделәр мине түрәләр.
Әмма никтер серле рәвешләрдә
(Аңлап микән, әллә ничекме)
«Өлкән агайларым» ябып торды
Керим дигән һәрбер ишекне.
Эти, эти! Нык булса да минем
Синнән күчкән холык-җисемем,
Киртә булды язмыш юлларымда
Син куштырган матур исемем.
Тамырымны истә тотып уздым
Тормышымда һәрбер мизгелне,
Шуңа, ахры, явыз канун рухы
Һәр адымда үзен сиздерде.
Рәхмәт сиңа, эти, үстергәнсең
Киң күңелле итеп улыңны;
Шуңа күрә явыз бәндәләргә
Үчләнүдән өстен булдыммы?
Бүген дә шул, йөрәгемне назлап,
Тавыш килә синең тарафтан:
«Дус яшәгез җирдә. Хак Тәгалә
Һәммәбезне тигез яраткан...»

3

Әйтә идең: «Чабышмагыз,
Тулсын, диеп, кесәбез;
Һөнәр белеп, җырлар сөеп,
Китап укып яшәгез.
Мал муллыгы – фани байлык,
Рух байлыгы – чын байлык...»
...Аһ, әтием, бигрәк бүтән
Бүген безнең чынбарлык.
Һөнәр сөйсәң – шыр тиле син,
Шигырь сөйсәң – хөрәсән;
Син килмешәк бу тормышта,
Сатулаша белмәсәң.
«Вөждан», – дисәң, – исәр мәхлук,
Хәйлә белсәң – рас галим;
Китаплылар – ачлы-туклы,
Хисапчылар – господин.
...Тик шулай да хаклыгыңа
Мин ышанам, әтием.
Юк байлыгым, ләкин дөньям
Хәзинәгә бай минем:
Бар дөньямда синең акыл,
Тарих дәресләре бар,
Тукай теле, Тукай җыры,
Тукай варислары бар.
Сафлык сөеп, язлар көтеп
Уза минем көннәрем;
Синең эзләреңнән атлыйм,
Тугры сиңа йөрәгем.

4

Ничәнчедер тапкыр
Бәреп екты язмыш.
Янды тәнем, акты яшьләрем.
Түздем. Миңа дошман кулы таныш, –
Шәфкать сорап бер сүз дәшмәдем.
Бусы да бит, әти,
Синең васыятең, –
Мин тәкрарлыйм кочып ташыңны:
«Егылсаң да бетеп хәл-куәтең,
Залимнәргә имә башыңны».
Ничә тапкыр миңа,
Сүнәм дигән мәлдә,
Фаразымда: «Ян!» – дип эндәштең;
Ничә тапкыр упкын чикләрендә
Терәк булды миңа киңәшең!
Ничә тапкыр сынып,
Янә торып бастым.
...Килер бер көн – бәлки, торалмам.
Тик, әтием, йокың тыныч булсын, –
Залимнәргә барып соранмам.

## УЛЫМА

Тук үстек без. Ләкин әниебез
Күп сөйләде узган чор гарен;

Ач елларда язгы басуларда
Күкәриннәр җыеп йөргәнен.

«Тишек башмак бата былчыракка,
Персидәтел артта сүгенә...
Калса да шул еллар бик еракта,
Онытмагыз аны бүген дә».

...Үсеп җиттең, улым. Күңел әрни:
Бурычларны ничек түләргә?
Дәү әниең әйткән гыйбрәтләрне
Онытканмын сиңа сөйләргә.

Син шул кыйссалардан мәхрүм булдың,
Язмыш сиңа булды мөлаем,
«Монтана»лы чалбар кигән балам,
Рэп-рок тыңлап үскән малаем!

Дөрес, ипле синең нигезләрең,
Саф йөрәгең, менә шуңа да
Каным синдә үзе уяныр, дип
Өметләнеп яшим дөньяда.

Килер бер көн – тартыр тамырларың,
Туйдырырлар сине ят җырлар;
Бер гүзәл моң булып хәтереңдә
Уяныр лар узган гасырлар.

## КАЙТЫП БАРАМ

Йөрәк дулый. Күңелемдә
Әллә челлә, әллә буран...
Майның якты бер көнендә
Туган илгә кайтып барам.

Ара якынлашкан саен,
Ыграк әрни иске ярам.
Вөҗдан яралары аша
Туган илгә кайтып барам.

Туган йортым, исән әле
Син очырган юньсез балаң!
Ачы үкенүләр аша
Туган илгә кайтып барам.

Мине көтеп моңайгандыр
Ике каберле бер алан.
Кабер кочып елар өчен,
Туган илгә кайтып барам...

## ГОМЕРЕМ

Гомерем туры килде шыксыз чорга,
Ә тарихым борын-борыннан.
Болгарларда, узган гасырларда
Табылмаган миңа урыннар.

Анда сугыш, монда ызгыш кыза.
Шул сәясәт-мөртәт сагызы...

Туган телсез, туган җырсыз уза
Көннәремнең уннан тугызы.

Безнең китаплар юк кибетләрдә.
Менә тормышыбыз көзгесе:
Вәсвәсәли уңган егетләрне
Хәмерләрнең төрле-төрлесе.

Туган илдән китап алдырырга
Бик саеккан безнең кесәләр.
Татар сабыйлары бакчаларда
«Ладушки» дип җырлап үсәләр.

Күрше милләттәшем минем белән
Кичә сөйләшкәләп маташты.
Башлы егет – Есенинны белә,
Әмма ишетмәгән Такташны.

Шул хәлләрдә карт-карчыклар яши.
Зиһеннәре ничек таралмый?
Китек тормыш күрә кардәшләрем,
Тамырларын эзли, табалмый.

Мин «агартыйм» дидем, мин тырыштым.
Ләкин ятлар – зәһәр терсәкле:
Күптән түгел миңа бер танышым
«Милләтче» дип йодрык күрсәтте.

Шулай яшим. Охшамады гасыр.
Бездән, ахры, бәхет борылган.
Гомрем туры килде ямьсез чорга.
Ә тарихым борын-борыннан…

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫ УКЫГАНДА

«Курчак туе» дигән сүзе –
Безнең ялган хозурлык,
Безнең затсыз кәпрәюләр,
Безнең юньсез горурлык.

Кайсы канлы, кайсы көлке
Безнең курчак туйлары.
Күпме айнып үкенсәк тә,
Җаннар уйнап туймады.

Бүген, тәмам уяндык, дип
Ду киләбез шатланып.
Ягъни акыл керде хәзер,
Ә узганнар – хаталык.

...Әмма нигә шөбһә баса
Кара янган күңелне?
Безнең бүген кылган эшләр
Курчак туе түгелме?

## ҖӘЛИЛ СУРӘТЕ

Сабый чакның кайбер мизгелләре

Еллар буе китми башымнан.
Сүз чыкканда, безгә кырын карап,
Пышылдады зурлар: «Сатылган...»

Әллә нинди хаста туган иде
Яшь җанымда шушы сүзләрдән:
«Исән икән… «Теге як»та яши…
Яшеренә… Исемен үзгәрткән…»

Әмма тиздән тарих гаделлеге
Бик гыйбрәтле сабак өйрәтте, –
Хәтеремдә: указ. Журнал бите.
Алтын йолдыз. Җәлил сурәте.

Еллар узды. Тәкъдиркәем мине
Анда бәреп, монда ыргытты.
Бу дөньяның явыз утларыннан,
Ачыш ясап, таптым чынлыкны.

Без бит иң-иң батыр егетләрне
Сау башлары белән түгел лә,
Гүр ташлары белән саныйбыз.
Туксан тугыз канлы газап аша
Үтсәң генә сине таныйбыз.

Күпме булса дәртең, шулкадәрле
Хәтәр оча дошман уклары.
Пакь йөрәкле адәм баласының
Авыр була тормыш сукмагы.

Без үзебез аңламаган эшне
«Ап-ак җирдә шакшы тап» дибез,
Әүвәл бәреп егып таптыйбыз да
Соңра күккә чөеп мактыйбыз.

Кардәшләрем! Ә без бүген менә
Аңлыйбызмы тарих гыйбрәтен?
Кичер, Җәлил! Чыкмый хәтеремнән
Иске журнал битләрендә күргән
«Жырларым» һәм якты сурәтең.

## МӘТРҮШКӘЛЕ ЧӘЙ

Мәтрүшкәле чәйләр эчеп алыйк,
Алан уртасында җәелеп.
Чәйләр белән тәмен татып калыйк
Бу бик кыска Урал җәенең.

Нидер сөйли җилгә назлы каен, –
Толымнары бигрәк сөйкемле.
Каенкаем! Сине күргән саен,
Яшьлегемә кайтам шикелле.

Казан каеннары чакырса да
Ерак почмагыннан хәтернең,
Яшьлеккә дә, туган якларга да
Кайтып булмас, ахры, кадерлем.

Менә шулай, җәйге аланнарда
Мәтрүшкәле чәйләр эчәрбез;

Туган үскән илгә кайталмагач,
Торган җирне туган итәрбез.

## ТУФАН

Кемнәр – аңлап, кемнәр – аңламыйча,
Куандылар ирек җиленә.
Канга баткан йөрәккәен учлап,
Туфан кайтты туган иленә.

Ул ялкындай дөрләде дә сүнде.
Ә без исә, маңка малайлар,
Туфаннарның өметен акламадык,
Азатлыкның кадерен сакламадык,
Каберләрне таптап, корып салдык
Алтын рәшәткәле сарайлар.

Алтын читлек рәхәт бирми җанга,
Асыл чорны күңел сагына.
Туфан сөйгән, Туфан гизгән күктә
Агыла да болыт, агыла…

## КҮРШЕ МАЛАЕ

Ул үзгәргән. Дөнья модасының
Соңгы сүзе белән киенгән.
Һичкем әйтмәс чыккандыр, дип, үзен
Шәмаилле авыл өеннән.

«Үзгәргәнсең, дисең? Шулайдыр шул.
Артта калып булмый тормыштан.
Китап укып туйдым. Хәзер менә
Сәүдә кырларында «сугышам».

Ташла җырларыңны, бу дөньяда
Иң зур бәхет – акча бит ул, Ирек!»
...Ә көтүдән сыер кайтмый калса,
Басулардан бергә эзли идек…

## САБАН ТУЕ ТАҢНАРЫ

Керфегемне назлап сөйде
Нуры җәйге шәфәкъның.
Башкаемны мендәремнән
Күтәрдем дә шаккаттым.

Сабан туе нигъмәтләре
Бизәп тора өстәлне;
Әллә бу ал пәрәмәчләр
Түтәлләрдә үскәнме?

Һич юк. Безнең әниебез,
Торып иртүк эңгердән,
Мичне ягып, бәлеш куеп,
Сыер савып өлгергән.

Үтүкләнгән ак күлмәгем

Чиста, пөхтә, сөйкемле;
Әнә яңа кәләпүшем
Күтәп алган бу көнне.

Иртүк күзен тырнап ачкан
Авылдагы һәр сабый.
Колга тотып, сөлге җыеп
Йөри Габдери абый.

...Кояш. Моңнар. Өстәлләрнең
Бәлешләре, баллары.
Менә шулай истә калган
Сабан туе таңнары.

* * *

Күрсәтте лә дөнья миңа күрмәгәнне, –
Уй-карашларымның килде асты өскә.
Бу җиһанның өч фәненә мин өйрәндем:
Ышанмаска, курыкмаска, теләнмәскә.

## КАЙТУ

Утыз елдан, утыз хәсрәт аша,
Җитмеш җиде киртә аркылы,
Җәрәхәтле йөрәгемне учлап,
Күңелләрем шунда тартылып,
Авылыма кайттым. Өлкәннәрнең
Киңәшләрен санга сукмадым.
Әмма кайтып акылымнан шаштым,
Танымагач мәктәп сукмагын.

Авылкаем! Нәрсә булган сиңа,
Урамнарың нигә үзгәргән?
Мин, ымсынып, яшьлегемне эзлим
Ят йөзләрдән, салкын күзләрдән.

Әмма таба алмыйм, таный алмыйм, –
Таулар иңгән, күлләр корыган.
Хуш ис түгел, тузан исе генә
Оча карабодай кырыннан.

Әй авылым! Әллә газаплыймы
Вөҗданыңны авыр бер гаеп?
Төсе уңган болынкайны ярып,
Шыксыз чокыр ята ыржаеп.

Дуслар, дуслар! Хыяллансак та шул
Туган якны тиңләп бишеккә,
Табып булмый янган бәхетләрне,
Кайтып булмый узган яшьлеккә.

Хәсрәт кичермәгән аңыгызга
Барып җитсен минем үгетләр.
Китмәгез лә инде, ә китсәгез –
Кайтмагыз ла инде, егетләр!

## БИК ЕРАКТА…

Бик еракта, бик еракта –
Ослан тавы, Кабан күле;
Ямьле фигыль, саф җөмләле
Тукай җыры, Такташ теле.

Зур хакыйкать, күп белемнәр
Алдым күрше рус теленнән.
Мин яхшырак беләм аны
Русларның да бик күбеннән.

Ләкин кайчак тын кичләрдә
Кинәт калка уй-хатирә:
Әллә әрләп, әллә җәлләп,
Таныш җырның моңы килә.

«Галиябану, сылуым-иркәм…»
...Истәлекләр – зәңгәр җилкән,
Урал кичеп кайтып керсәм,
Авылым мине таныр микән?

«Каз канаты ап-ак була...»
...Чигәләргә чаллар куна,
Дәвалар юк, дарулар юк
Күңелләрем сызлануга.

«Күк күгәрчен күктә уйный,
Күләгәсе җирдә уйный…»
...Кайтсам да шул Мәмдәлемә,
Яшьлегемә кайтып булмый.

Илебез зур, һөнәрләр күп:
Кемгә – табыш, кемгә – сагыз.
Бәхет эзләп, мавыгып йөреп,
Тамырларны онытмагыз.

Онытмагыз, онытмагыз
Туган болыннарның җилен,
Ямьле фигыль, саф җөмләле
Тукай җырын, Такташ телен…

## КАЗАНДА КУНАКТА

Өрәңгеләр монда яфрак ярган,
Бездә шәрә әле каеннар.
Аһ, Казаным! Синдә – кояш. Ләкин
Йөрәгемдә сиңа зарым бар.

Синдә – язлар, бездә суык әле.
Синдә – якты, бездә – караңгы.
Әйт, Казаным, ничек татар итеп
Үстерим мин газиз баламны?

Синдә – гыйлем. Бездә – рухи ачлык.
Чирли татар, булмый терелтеп.
Җыелганда бергә, аңлашабыз
Ике ярым телне бер итеп.

Шатлан язга, Казан! Тик аяныч
(Аңлашылыр микән уйларым) –
Таулар артындагы улларыңа
Барып җитми синең нурларың.

## КИЛЕП КҮКРӘГЕМӘ СЫЕНСАҢ

Бер тын почмак та юк бу шәһәрдә...
Бир, кулыңны учлыйм, ичмасам.
Кеше күрә, дисең, әй күрсен лә,
Йөрәккәем сызлый, шушы көндә
Күкрәгемә сине кысмасам.

Чиктән ашып дәртем, тынсыз калам,
Тәнең тигән чакта тәнемә;
Шул мизгелдә үзем өр-яңадан
Гашыйк булам тормыш ямենә.

Онытыла сине күргән мәлдә
Бу җиһанның авыр моң-зары;
Чумса йөзем йомшак чәчләреңә,
Эри җанның соңгы бозлары.

Күзләремне синнән ала алмыйм,
Нинди тылсым синдә бар, иркәм?
Килеп күкрәгемә сыенсаң, дим,
Иңнәремне кочып сарылсаң, дим,
Шуннан да зур шатлык бар микән?

## ИКЕ ҖӘЗА

Туган якны хәтерләтә һәр таң,
Бергә йөргән тавын-үзәнен.
Җәйле таңда яңгыр булып яусам,
Танырсыңмы мине, гүзәлем?

Йөрдек бергә кызгылт урманнарда,
Сөеп өрәңгеләр ялкынын.
Көзге яфрак булып балкыганда,
Танырсыңмы мине, алтыным?

Без куанган идек карлы көнгә,
Бәхетләрнең теләп иң зурын.
Карлар булып кунсам керфегеңә,
Танырсыңмы мине, күз нурым?

Гөлгә чума иде язын бакчаң,
Шул бакчага оча уйларым.
Түтәлеңдә чәчәк булып атсам,
Танырсыңмы, язгы хыялым?

Ике җәза бирде миңа язмыш,
Өзә алмыйм тәкъдир богавын.
Берсе аның – кавыша алмавыбыз,
Икенчесе – оныта алмавым.

## КӨЗ

Көз аерды безне.

Тагын таллар
Яфракларын җиргә салдылар.
Әйтелмәгән сүзләр күңелләрдә,
Җырланмаган җырлар калдылар.

Күз аерды безне. Көн сүрелде.
Уртак шатлыгыбыз киселде.
Түтәлләрдә гөлләр шиңеп калды,
Җырланмаган җырлар шикелле.

## КЫШКЫ ТАМЧЫ

Күптән кипте яшем күзләремдә,
Тоныкланды үпкә таплары.
Яшергәндәй буран кышкы эзне,
Яраларны вакыт каплады.

Нигә хәзер миңа елмаюың,
Ничек инде синә шат карыйм,
Кышын тамган җылы тамчыларга
Яз килде, дип, нигә шатланыйм?

Чын яз килсен, язны көтим әле,
Ул яз миңа назлап карасын.
Җылы тамчы кышын – ялган тамчы,
Ачма иске йөрәк ярасын.

* * *

Үзгәрмәгән, ахры, җисемем минем:
Тагын миңгерәтте яз җиле.
Элгәре мин яшь һәм юләр идем,
Бүген исә карт һәм шыр тиле.

## ГӨЛӘП

Коелса да гөләп чәчәкләре,
Хуш ис калган бераз куакта.
Без дә шулай: калган кебек назың,
Булсаң да син үзең еракта.

Алып китте соңгы хуш исләрне
Җәй җилләре. Саргайды хатлар,
Өметләрем янды. Килеп җитте
Әрем чәчәк атар вакытлар.

## ТАЙГАДА

Йөрәгемне, йөрәгемне аңла.
Күзләремә сагыш түгелгән.
Тик бер җөмлә, нәни бер хат миңа –
Давыл китәр күңел күгемнән.

Һәр көн менә почта вертолетын
Көтеп алам, күреп ерактан.
Өмет белән карап каршы алсам,
Үпкә белән кире озатам.

Дуслар мәшгуль, хатлар укый алар –
Эчә татлы дөнья рәхәтен.
Бер мин генә тагын гәзит укыйм,
Гүя гәзит баса хәсрәтем.

Тик бер җөмлә… Җаным түзмәс, ахры,
Күпме зыян, күпме файдасы.
Кайтып китәрмендер Казаныма,
Чәнчелепләр китсен тайгасы.

...Сагышымны, сагышымны ишет.
Күзләремдә шатлык сүрелгән.
Тик бер җөмлә, тик бер кыска җөмлә –
Болыт китәр күңел күгемнән.

## КӨЗ БАШЫ

Хәсрәт килгән кебек көтмәгәндә
Җан тетрәтеп килде көз башы;
Күл ярына барып йөрсәм дә шул,
Сагыш кына минем юлдашым.

Ни булды бу? Якты болыннарда
Әллә үзем генә йөрдемме?
Эссе җәйнең кайнар мизгелләрен
Төшләремдә генә күрдемме?

Бәхетемнең татлы валчыклары
Комга әверелеп суынды.
Саташулы уйларымда гына
Учларымда тоям кулыңны.

Бугазымны буган төер кебек
Көз җилләре кыса тынымны…
Ник ашыктың, нигә тыңламадың
Соңга кадәр минем җырымны?

Көз көз инде. Алтын дисәләр дә,
Синең карашыңдай салкын ул.
Язлар кайткач, назлар кайтыр микән,
Насыйп микән кабат талпыну?

Алсулана офык, янган кебек
Шәфәкълары җәйге кичләрнең.
Эзләрең юк. Комда эзләр калмый.
Ә йөрәктә калса, нишләрмен?

Монда тынлык. Гүя җәйге хисләр
Дөнья куеп, комга күмелгән.
Күл ярының җырлы-серле дәрте
Җәй челләсе белән сүрелгән.

Аргы якта ялгыз учак яна,
Хәтерләтеп ләззәт көннәрен.
Бирге якта исә җил туздыра
Учагымның суык көлләрен.

...Бугазымны буган төен кебек,
Көз җилләре кыса тынымны.
Туңам бүген, бәгърем, – сиңа бирдем
Йөрәктәге бөтен җылымны.

## ҮПКӘЛӘШКӘЧ

Керсәң төшемә елмаеп,
Әй куанам уянып!
Шук сүземне, сәбәп табып,
Булмасмы кире алып?

Дуамаллык, юләрлекнең
Кайда булды чикләре?
Авыр сүзне әйтмәс өчен
Ихтыярым җитмәде.

Үз-үземә: «Назлап сөй, – дим, –
Кайда синең җан зурлык?»
Ә күңелдә – әллә нинди
Таштай каткан горурлык.

Нигә кирәк бу мәсхәрә,
Чиста суда болганыч?
Төштә генә ләззәтләнәм,
Төштә генә юаныч.

...Шулай уфтанып йөргәндә
Елмаеп куйдың, иркәм.
Мин күргән төшләрне әллә
Син дә күргәнсең микән?

## АЛИҺӘМ

Чыпчык малайлары куаныша
Алсу таңга, зәңгәр иртәгә.
Нинди төшләр күреп елмаясың,
Борын очың төртеп җилкәмә?

Ак мендәрдә – кара толымнарың,
Күкрәгемдә – кулың җылысы.
Янам – әллә бер җырлыйсы килә,
Әллә инде үксеп елыйсы?

Кайный хисләр, зиһенемне бутый
Сөюемнең татлы әфьюны;
Бер уй анык: фәкать синең белән
Язмышымның булыр саф юлы.

Минем сөюемдәй булмагандыр
Яну җирдә тарих башыннан.
Ходаем да үпкәләмәс кебек,
«Алиһәм», – дип үпсәм кашыңнан.

## ЯЗ

Алып китте апрель йөрәгемнән
Сагыш дигән ачы сагызны;
Кыш тудырган суык уйларымны
Яз кояшы эретеп агызды.

Керфегемдә тамчы җемелдиме?
Димәк, рухым гарьдән арына;
Бозлы җилдә туңып каткан күңелем,
Яшим, диеп канат кагына…

## КӨНЛӘШҮЕМ – СӨЮДӘН

Хыянәт ул – кыямәт ул,
Аның тәмен беләм мин;
Шуңа аны дуска түгел,
Дошманга да теләмим.

Синсез үтсә бер сәгатем,
Шөбһәләнәм шул, иркәм:
«Алай микән, болай микән,
Әллә тегеләй микән?»

Көнләшәсең, дип рәнҗемә,
Көнләшүем – сөюдән,
Минем өчен җирдә синсез
Бәхет югын белүдән.

Көн буена фаразлаган
Уйларым чынга ашса,
Тулган иреннәрең белән
Иреннәрем очрашса, –

Төнге күктә кояш калка,
Көзен шыта бөреләр,
Булыр-булмас гөнаһларың
Кичерелеп эриләр.

Йөзләреңдә – алсу шәфәкъ,
Күзләреңдә – таң гына,
Дулкыннарым, миңа күчеп,
Күкрәгемне яндыра.

...Тәнемнең һәр күзәнәге
Сине тойган чакларда
Көнләшмим дә, шикләнмим дә,
Ышанмыйм да юк-барга…

## КАЙДА БУЛДЫ УЙЛАРЫҢ?

Бердәнберем, назлы ярым,
Таңнарымның былбылы!
Күңелләрең, хыялларың
Миндә генә булдымы?

Йөрәгеңнең тибешләрен

Тойган чакта кулларым,
Кайда булды фаразларың,
Кемдә булды уйларың?

Сизгән чакта йөрәккәем
Карашыңның утларын,
Уйларыңны белмәгәем,
Диеп оча котларым…

## ОЗАТУ

Тагын сине озатырга бардым
Шаулы мәйданына вокзалның.
Иреннәрең тәме калды иренемдә,
Үзең ашыгып күздән югалдың.

Ләззәт минутларын озайтырга
Сәбәп тапмый тагын тилмердем.
«Китмә», – диде күңелем,
«Сау бул», – диде телем;
Бәхет нурын үзем сүндердем.

Әйтер сүзем тагын әйтелмәде,
Кемгә кирәк булды бу түзем?
Мәйдан шау-шуында юкка чыктың,
Иләсләнеп калдым берүзем.

## МАНЗАРА

Урамнардан көтү күптән узган,
Юлдан купкан тузан басылган,
Көн буена зәңгәр күкне гизгән
Болытлардан һава арчылган.

Елмая да соңгы нурын бөркеп,
Кояш кача басу артына;
Кыр шәүләсе төшә, тау шәүләсе
Урамнарга, ишегалдына.

Көнбатыш як керә түтәлдәге
Пешеп килгән җиләк төсенә,
Рәхәтләнә дөнья һавадагы
Печән исе, җиләк исенә.

## ТАШКЫН

Уза тормыш.
Ага бөтерелеп,
Ага дулап вакыт ташкыны.
Сүнмәс йөрәк, тынмас җаннар бара
Аннан узып, аннан ашкынып.

Гүя ташкын,
Гүя язгы ташкын
Актарыла, дулый, сикерә,
Ватык кораб, ярык көймәләрне

Атып бәрә елга читенә.

Шулай ага вакыт, ага тормыш,
Аккан кебек шаулы елгалар.
Сүнә – кемнәр көчсез, ихтыярсыз.
Тик кыюлар җиңеп чыгалар.

* * *

Ташкыннар да кичтем, янгыннар да…
Сыкы төште кара чәчемә.
Мин дә килеп җиттем шагыйрьләрнең
Һәлак була торган яшенә.

Тик бурычым минем күп халкыма,
Бик күп әле рухи хисаплар.
Шуңа күрә мәңге бу дөньяны
Ташламаска дигән исәп бар.

## ДУСКА

Гитарасын чиртә егет.
Моңсу күзләр – кылга кылдан.
Ага авыр ташлар кебек
Авыр сүзләр, – хәсрәт тулган.

Доцент аны тагын бер кат
Имтиханнан кире куган:
«Бар, кайт, – дигән, – йөрмә юкка,
Белмәгәнгә өчле куймам…»

Авыр, авыр кыенлыкка
Күнекмәгән яшь егеткә…
Елый кыллар, сүзләр ага
Символ булып көчсезлеккә.

Уян, егет. Күтәр башың,
Куеп тор син гитарыңны,
Ку үпкәңне, җиң хисләрең,
Ал кулыңа китабыңны.

Шиңмә инде, йә, кыю бул.
Минутыңны әрәм итмә!
Тормыш – ташкын.
Тормыш бит ул
Көчлеләрне хөрмәт итә.

## БАБАЙ ХИКӘЯСЕ

«Чиләбедән беркөн кайтып барам.
Оча поезд. Рәхәт күңелгә.
Дубровкада бер исерек керде, –
Унсигез дә юктыр үзенә.

Япь-яшь үзе, ләкин сүгенергә
Кече яшьтән, ахры, өйрәнгән.
Уйлап куйдым: их, нарасый, димен,
Хәмер эчеп бала кинәнгән.

Әдәп, оят качкан. Яшь кызларга
Бәйләнергә егет тотынды.
Җитәр, мәйтәм, кирәк тындырырга
Көтелмәгән мондый шаукымны.

Зур тимерле солдат каешымны
Ашыкмыйча салып билемнән,
Ипләп тотып берне селтәндем дә,
Шалт тегенең йомшак җиренә!

Шартламады гына инде малай,
Битләренә кызыл йөгерде,
Юашланды тагын күреп алгач
Каештагы авыр тимерне.

Сабый чакта каеш иснәтергә
Оныткандыр, ахры, атасы;
Шулай менә, инде ирексездән
Мин төзәттем аның хатасын…»

Тыңладым да картны, уйлап куйдым:
Тиз тынырлар иде тавышлар,
Күбрәк булсын иде шундый картлар,
Күбрәк булсын иде каешлар!

## ЯЗ НУРЫНДА ТАПКАН…

Уза еллар тәрәзәмнән карап.
Канатымны алар каерды.
Яз нурында тапкан дусларымны
Көз җилләре миннән аерды.

Мин аларны зәһәр давылларда
Соңгы җылым биреп сакладым…
Көзге җилдә туңып, дусларымда
Җылынырлык ышык тапмадым.

Дуласын ла җилләр, япсын вакыт
Яраларын узган көннәрнең!
Гомеремә дуслык җитсен өчен,
Мин дусларны көзен эзләрмен…

## КӨЗ

Шыгыр-шыгыр диеп ыңгыраша
Ял паркында ялгыз бер таган.
Көзнең сары каен яфраклары
Чал чәчемә минем охшаган.

Мәктәп болдырында – үсмер яшьләр,
Күзләрендә – тормыш ләззәте.
Шуңадырмы бигрәк мәрхәмәтсез
Талый мине шиңү хәсрәте.

Килер көннәр – яшел каеннарның
Толымнарын назлап тарар яз.

Яшьлек төсе керер табигатькә,
...Минем чәчләр генә каралмас.

## ХЫЯЛЛАР

Яшьлегемдә корган мең хыялның
Аштырдыммы чынга тик берен?
Язгы өмет белән көзге чынлык
Арасында калды гомерем.

Ә нигә соң әле бүген дә мин
Хыялланып тагын шатланам?
Яз үтмәгән, ахры, көз җитмәгән,
Болыт кына күкне каплаган.

## МИНЕМ ИСӘ…

Куанасың бүген иркенлеккә,
Торгын еллар зарын хәтерләп:
Язганыңны өстәл тартмасында
Саклап яшәгәнсең кадерләп.

Минем исә шәрә өстәлләрем,
Соры еллар, рухи ярлылар
Аягымнан бәреп ектылар да
Каләмемне тартып алдылар…

## ЯШИМ

Күнеккән хәл инде: бирде язмыш
Борыч белән бутап балларны…
Киткән жирдә беркем озатмады,
Кайттым – һичкем каршы алмады.

Гомер буе бер хакыйкать ятлыйм:
Тегендә дә ят мин, монда да.
Тик шулай да яшим әле, яшим,
Өмет корып яшим дөньяда…

## АЕРЫЛЫШУ

Хөкем узган. Карар – кулда.
Үпкәләпме язмышка,
Нидер көткән кебек, икәү
Чыгып баскан баскычка.

Еллар буе бергә яшәп
Күптән кушылган каннар.
Кичә бер җан иде алар,
Бүген – аерылышканнар.

Яз таңында туган хисләр
Туңып шиңгәнме кышта?
Хатын – чибәр, ир – мәһабәт,
Ни җитмәгән тормышта?

Ике йөрәк, чирдән айнып,
Аптыраган гүяки.
И дусларым, кочаклашып
Үбешерсездер, бәлки?

Онытыгыз вак-төякне,
Ачуларны, зарларны;
Хәтерләгез бергә сайрап
Каршылаган таңнарны.

Юк, булмады инде. Хәтта
Кысмады да кул кулны.
Җәрәхәтле ике йөрәк
Ике якка омтылды.

Нинди хисләр кичергәндер
Кара янган бу җаннар?
Кичә бергә иде алар,
Бүген – аерылышканнар.

СОРАМАГЫЗ…

Сорамагыз, яшең ничә, диеп,
Саргайсам да күзгә күренеп,
Һәр ел саен тулган яңа санга
Һич өлгерә алмыйм күнегеп.

Чынлап әйтсәм – кырык тулып узды.
Ә күңелдә – һаман унҗиде,
Әллә ничек итеп җиңеләйтә
Уйларымны язның тын җиле.

Шундый минутларда һич сәбәпсез
Елмаерга бер дә хурланмыйм;
Урамнарга чыксам, узган-барган
Һәр чибәргә гашыйк булам мин.

Минем иләс авыз ерык булгач,
Йә елмая алар, йә көлә:
Бәлки, нинди юләр бу, диләрдер,
Бәлки, киресенчә… кем белә?

Тик шулай да… кырык кырык инде.
Туймаса да йөрәк ялкыннан,
Иллесе дә, каһәр, күренә бит
Дулап аккан көннәр артыннан.

* * *

Миәсләргә төшәбез дә, Таганайга менәбез,
Юл күрсәтеп балкып торса, моң йолдызы –
Минәҗев.
Үкси-үкси елыйбыз да, эчләр катып көләбез,
Елата да, жырлата да жыр чишмәсе – Минәҗев.
Җаннар сусап тилмергәндә, Нил янына киләбез,
Сусаганда ләззәт бирә моң чишмәсе – Минәҗев.

* * *

Баер өчен яшисеңме җирдә,
Әллә яшәр өчен байыйсың?
Әллә баюың да, яшәвең дә
Бу җиһанның бер зур кайгысын
Юк итәргә сиңа юл ачамы?
Иҗат ireклеге бирәме?
Йә ниятең тоташ гөлбакчалы
Итәргәме якын-тирәңне?
Әйтик, алтын сарай салдырырсың,
Җыеп бөтен дөнья акчасын…
Ә аннары нәрсә? Кайда кыйблаң?
Кайда мәгънә? Кайда максатың?

## ЮЛӘР ТАКМАКЛАР

Биш тәңкәләр, ун тәңкәләр
Сандыгымда саклана.
Ике тартма шырпы алдым
Гомер җыйган акчама.

Кайгырмагыз, әгәр сезгә
Башыгыз буш, дисәләр:
Буш баш белән яшәп була,
Буш булмаса кисәләр.

Фантастика димә, күрсәң
Очкан тарелкаларны.
Боткам да юк, акчам да юк, –
Мин очырдым аларны.

Пенсиябез җитми диеп
Катмый безнең башыбыз:
Президентның вәгъдәләрен
Ашка турап ашыйбыз.

* * *

Аһ, син, мескен адәм балакае,
Хак сүзләргә колак салмыйсың;
Әтиеңнең изге вәгазьләрен
Үзең әти булгач аңлыйсың.

Балаң үскәч вәгазь укыйсың да,
Кайда зыян, кайда файдасын
Аңлаттым, дип, күңел юатасың.
Ә балаңның уе кайда соң?

Үзең яшьли аңламаган сүзне
Балаларың ничек аңласын?
Агачыннан ерак төшәмени
Алмагачның пешкән алмасы?

## ГОМЕР

Берәү генә булып чыкты гомер…
Дөрләп китмәгәе мендәрем.

Вак-төяккә, фани байлыкларга
Әрәм булды алтын көннәрем.

Кичә генә кебек тормышымның
Капкасыннан кереп киткәнем.
Инде ипләп яши башлыйм, дисәм,
Аръягына барып җиткәнмен.

Уйнап-көлеп, җырлап-биеп йөрдек,
Яшәү йомгакларын сүткәндә…
Кайтып алларына тезләнерлек,
Кичерегез, диеп үтенерлек
Кешеләрем күп шул үткәндә.

* * *

Сибелә чәчәк, сибелә чәчәк,
Сибелә чәчәк – көз микән?
Язда гөрләп, җәйдә яшьнәп
Яшәгәннәр без микән?

Ком бураны, ком бураны
Күз ачырмый дулады.
Язлар акты, җәйләр янды,
Нәүмиз ярлар елады.

Тал әйләнә, тал әйләнә
Очып китәрдәй булып;
Газиз яшьлегем, килсәнә
Көз артыннан җәй булып.

Әй гөлбакча, әй гөлбакча,
Кара кашлар, ал ирен.
Яшьлегебез кире кайтса,
Белер идек кадерен…

## КӨЗ

Аң бирә көз җәйге ялкыннарда
Иләсләнгән һәрбер кешегә.
Гомерләрнең мәңге түгеллеген
Мыштым гына искә төшерә.

Минем исә кайный хыялларым,
Тормыш сөеп йөрәк тузгына;
Өрәңгенең комач яфраклары
Йөзләремне уттай кыздыра.

Шиңсә дә шул гөлләр түтәлләрдә,
Күңелемдә гөлләр сулмады.
...Җирнең җирән көдрәләре булып
Балкып тора усак урманы…

## БЕЛЕП ТОРГАН ИДЕК

Көз киләсен җәй буена
Белеп торган идек шул,
Тик шулай да ун гомерлек

Хыял корган идек шул.

Хәлләр бетте, дәртләр сүнде,
Кайнар көннәр сүрелде;
Яфракларның сарылары,
Чәчнең чалы күренде.

Минем талган йөрәгем дә
Әллә инде ял сорый?
...Күлнең шадра көзгесендә
Шәрә таллар калтырый.

* * *

Алга, диләр, алга, диләр,
Алга таба әйдиләр.
Алды кайда, арты кайда, –
Анысын никтер әйтмиләр.

* * *

Юк, картаймыйм, әле һаман туры билем,
Иләсләтә сылуларның татлы ирене.
...Автобуста бер чибәргә баккан идем,
Ул, сикереп торып, миңа урын бирде.

* * *

Өметләрем шытып сулды,
Кайнар үчләр кайтмады,
Шәфәкъларым алсуланды,
Әмма таңнар атмады.

## ҮЗ КҮРДЕЛӘР

Үз күрделәр мине шома
Йөзләр, юан биллеләр:
Йөгәнсез атымны алып,
Атсыз йөгән бирделәр.

## КИЧЕРДЕҢМЕ ИКӘН?

*(Җыр)*

Әниемнең моңлы кыйссаларын
Ишеткәндәй булам, саташып;
Төшләремдә йөрим туган өйнең
Каралтыларында адашып.
Бик җентекләп нидер сораштырам
Баз артында үскән зелпедән;
Хәтеремнең шомлы эңгерендә
Әллә кемне эзләп интегәм.

Менә кайттым. Дәшми каберең.
Кичердеңме икән, бәгырем?

Рәнҗетмәдем кебек үскән чакта,
Итагатьле идем, ягымлы;

Әмма әллә нинди гөнаһ хисе
Гомер буе талый җанымны.
Рәнҗегәндәй булган мизгелләрең
Искә төшә тагын, тагын да.
Соңгы сулышыңда чакыргансың, –
Була алмадым шул яныңда.

Әнием, кайттым!.. Дәшми каберең.
Кичерденме икән, бәгырем?

## СҮРӘТ

Йомры түшле. Кеш тунынннан,
Бүрекләре камалы.
Белемнәре – ике диплом,
Акыллары – чамалы.

## СОҢАРГАН МӘХӘББӘТ

*(Җыр)*

Ялкыннарга төрдең чал башымны.
Ышанучан йомшак карашыңны,
Очрашмаган булсак та без элек,
Таныгандай булдым бер күреп.
Җәйләр узган, җиткән көзнең сагышлары,
Салмакланган тормышларның агышлары.
Нигә очрамадың яшьлегемдә,
Мәмдәлемдә, Идел ярларында?
Гомер буе сине сагынганмын,
Бер гомергә соңга калганмын.
Узды тормышның югалту, табышлары,
Йөрәкләрне өзә шиңү сагышлары.
Тәүге тапкыр күреп саф йөзеңне,
Таныгандай булдым яшьлегемне.
Син янымда бүген, янәшәмдә,
Ә яшьлегем – ерак җәйләрдә.
Узган җәйләр, җиткән көзнең сагышлары,
Салмакланган тормышларның агышлары.

## САРЫКҮЛ

*(Җыр)*

Көзге җилләр, дымлы җилләр
Тиң булганга җаныма,
Томан ярып чыгам иртән
Сарыкүлнең ярына.

Ялгызлыкта, нәүмизлектә
Көн артыннан көн ага.
Кайгыларсыз гына яшәп
Булмыймыни дөньяда?

Соры камыш. Ялгыз аккош.
Синсез тормыш – коры чүл.

Минем хисләремдәй моңсу
Сагыш күле – Сарыкүл.

Ялгызлыкта, нәүмизлектә
Көн артыннан көн ага.
Кайгыларсыз гына яшәп
Булмыймыни дөньяда?

Арабызда – Урал тавы.
Ятим калдык кебек без.
Сарыкүлнең томаныдай
Киләчәкләр өметсез.

Ялгызлыкта, нәүмизлектә
Көн артыннан көн ага.
Кайгыларсыз гына яшәп
Булмыймыни дөньяда?

## ХАТЛАР КӨТӘМ

Күпме яшәп җирдә, шуннан тәмле,
Шуннан ачы шөгыль тапмадым.
Кабат укыйм мәрхүм әтиемнең
Саргаеплар беткән хатларын.

«Ник язмыйсың, улым, йөрәк парәм,
Шушы микән тәкъдир хөкеме?
Хат-хәбәрсез менә узып бара
Гомеремнең тагын бер көне…»

...Выжлап очты еллар, сулды йөзем,
Чигә чәчләремә чал төште;
Үкенүләр узды, дигән идем, –
Үз балам да үсеп җитеште.

Язмышкайлар кабатлана икән,
Белгән булсам шуны мин алдан…
...Күз күгәртеп хәзер хатлар көтәм
Ерактагы газиз баламнан.

## ЯЗГЫ УРАМ

Әкрен генә кыш үткәрдем
Яндыргалап утынны.
Язгы урамны күрдем дә
Йөрәк тагын чукынды.
Һәр чибәрнең күз карашы
«Кил», – дип чакыра мине,
Әллә барысы миңа гашыйк,
Әллә үзем шыр тиле.
Чиктән аша хыялларым,
Көчләр кайный беләктә,
Картаюга урын юк шул
Сөю тулган йөрәктә.

## АҖАГАННАР

*(Җыр)*

Яшәү мәгънәсенә төшенергә
Омтылуым туса уемда,
Өянкеләр белән пышылдашып
Йөрим төнге Уел буенда.

Кушымта:

Салмак кына дулкынланып
Шаулый иген басуы;
Сискәндереп уйландыра
Аҗаганнар балкуы.

Аҗаганнар яшьнәгәндә,
Бөрлегәннәр өлгерә;
Матур илләр бик күп җирдә,
Тик туган ил бер генә.

Болындагы пөхтә кибәннәрдән
Җиләк исе килә, бал исе;
Шундый мизгелләрдә аеруча
Их, яшисе килә, яшисе!

Кушымта.

Туган ягым, иң кадерле җырым,
Күңелемнең изге кәгъбәсе!
Шул моңның мин нәни бер аһәңе,
Шунда, димен, Яшәү мәгънәсе.

Кушымта.

Шушы җирнең мин бер күзәнәге,
Шуңа күрә генә булса да,
Илем белән шатлык-михнәт чигеп,
Яшәүләре татлы дөньяда.

Кушымта.

## КЕШЕ

Якасыннан каптырса да
Әҗәл ташлаган ыргак,
Бер аягы гүрдә аның,
Берсе бии тыпырдап.

## КӨМЕШ ТУЙ

Давыллары дуласа да көзнең,
Якты булып ата таңыбыз.
Алтын туйлар әле ерак безнең,
Яшьни-яшьни яшәр чагыбыз.

Язмыш сукмагында юл ташы…
Көмеш туйлар – тормыш уртасы.

Ике әткәй белән ике әнкәй
Табыннарыбызның түрендә.
Йа Ходаем, гөрләсен лә гел җәй
Өлкәннәребезнең күгендә!

Уфтанмачы, газиз юлдашым,
Көмеш туйлар – тормыш уртасы.

Өч улыбыз тиңдәш бөркетләргә,
Күзләрендә – якты изгелек.
Назга юмарт булган йөрәкләргә
Артып кайта икән игелек.

Моңсуланма, газиз юлдашым,
Көмеш туйлар – тормыш уртасы.

Син – максатым минем, син – ләззәтем;
Сүнмәс, ахры, дәрт тә, теләк тә.
Бүген дә бит кайный мәхәббәтем
Картаймаган кайнар йөрәктә.

Язмыш сукмагында юл ташы…
Көмеш туйлар – тормыш уртасы.

## ШАГЫЙРЬ ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Шагыйрь җирдә яшәми ул,
Яшен булып кына яшьни.
Шагыйрь юлы кыска була,
Тик шигърият мәңге яши.

Тормыш авыр, шагыйрь – фәкыйрь.
Яшим дисәң , сыгыл, бөгел…
Шагыйрь ялланырга мәҗбүр,
Тик шигърият – ялчы түгел.

## ИКЕ ЧИБӘРГӘ МӘДХИЯ

Тагын тойдым тормыш тәмен,
Сиздем җирдә моң барын.
Эльвираның җырлаганын,
Резедәнең сөйләгәнен
Хәйран калып тыңладым.

Сокланудан телдән язам,
Чумып тойгы-хисләргә,
Күз нуркаем, син сөйләсәң,
Бәгырькәем, син җырласаң
Шушы язгы кичләрдә.

Бу ягымлы китапханә
Саф чишмәдәй күңелгә.
Сеңелкәем, җырласана,
Ә син, сеңлем, сөйләсәнә,
Мин – колыгыз бүгенгә.

Дөрли җаным, кайный каным…
Кайт, яшьлегем, бер яндыр!..
Резедәнең сөйләгәнен,
Эльвираның җырлаганын
Мәңге тыңлап туймамдыр.

## ЯШӘП ЙӨРГӘН БУЛДЫК

Бәхет капкалары терәксез лә,
Бер ача да язмыш, бер яба.
...Ялан күткә каеш буып, без дә
Яшәп йөргән булдык дөньяда.

Ачылмады безгә һичбер ишек,
Тик язмышны, имеш, алдадык.
Юләр саттык, комнан аркан ишеп,
Булмаганны бушка аударып.

Баш сау булса, бүрек табылыр, дип,
Елап, хафаларга төшмәдек;
Яшь буыннар ансат бөгелә бит,
Терсәкләрне җиңел тешләдек.

Шома йөзләр татлы итеп әйтсә,
Тиз ышандык һәрбер юк-барга;
Байлар бал эчкәндә, су эчсәк тә,
Сер бирмәгән булдык ятларга.

Ашыбызны ашап бетердек тә,
Яшебезне яшәп бетердек;
«Шома»ларны бәреп төшердек тә,
Егып, йөзләренә төкердек.

Хәзер намаз укып утырабыз
Гомер буе динсез кылангач;
Тик барыбер һаман алама без,
Эттән ач һәм беттән ялангач.

Вакыт дигән нәрсә – акча икән,
Гафилләрдән бик тиз кача икән:
Качты тормыш язы, узды җәй…
Гомер дигән нәрсә – җәфа икән,
Әмма үтә икән мизгелдәй.

## ЯРЫҢ КЕРСӘ ЯТЛАР КОЧАГЫНА…

Зар түгәсең, хатыныңны әрләп,
«Ни җитмәгән, диеп, тормышта?»
...Ярың керсә ятлар кочагына,
Аны гаепләргә тырышма.

Дөнья куып, алтын чыңнарына
Омтылганда бөтен өметең,
Яшен түгеп салкын мендәренә,
Ни уйлады хәләл җефетең?

Портфель тотып, эшкә багышладың
Һәр төнеңне, һәрбер иртәңне;
Нигә мәхрүм иттең кочагыңнан,
Нигә ялгыз иттең иркәңне?

Дуслар белән мыжлап кинәнгәндә
Ләззәтенә хәмер парының,
Сизденңме син назлы сүзгә сусап
Тилмергәнен сөйгән ярыңның?

Үзең: «Эшлим», – дигән сылтау белән
Дөнья балын шактый татыдың;
Сөю көтеп ялыкмасынмыни
Яз гөледәй чибәр хатының?

Яз чәчәге кебек гүзәл хатын
Көз җиткәнен көтеп ятармы?
Якын яры сөеп үз итмәгәч,
Үз иткәндер үзе ятларны.

Үз гаебең. Кемгә үпкәлисең,
Кемне тиргәп әрни бәгырең?
Үзең сакламаган хәзинәңнең
Бүтән ярлар белгән кадерен.

## ЕЛМАЕШЫЙК

Әйт, кадерлем, нәрсә булган?
Ач серең;
Ник моңайдың, ник коелган
Сөмсерең?
Җәйләр узды, ыржая көз,
Дисеңме?
Көзләр кебек саргаябыз,
Дисеңме?
Көз сарысы – бары шигъри
Билге ул;
Моңаерлык кайгымыни
Инде ул?
Көннәреңне юләр сатып
Туздырма,
Елап-шыңшып юкка вакыт
Уздырма.
Ни рәте бар яшь түгүнең,
Аптырап?
Күрә белү тормыш күркен
Татлырак.
Табигатькә ипләп карап
Үрнәк ал:
Шаулый, чәчен җилдә тарап,
Бөдрә тал;
Узып барса да әбиләр
Чуагы,
Кызыл, яшел, сары миләш
Куагы
Әй җемелди – камаштыра
Күзләрне!
Йөрәк бозың шул яктыга
Түзәрме?
Һич булмаса, миңа кара,
Гүзәлем,
Яшәү уты белән яна
Күзләрем!
Юлда, җилдә, яңгырларда
Арсам да,
Елмаям мин бу дөньяда

Һәр таңга.
Язмышның һәр халәтенә
Түзем мин.
Бу тормышның хәсрәте дә
Гүзәл, дим.
Әнә җилдә эзли ышык
Күбәләк.
Кил яныма, елмаешыйк
Бергәләп!

## УЙ

Ябышты бит тагын бугазыма
Бәла – сагыз;
Татлы хатирәләр юата, ди, –
Ышанмагыз.

Искә алган саен яшьлегемнең
Ерак күркен,
Томалана, авырая бара
Бүгенге көн.

## КИҢӘШ

Йөзең чытма, карап бу тормышта
Ялгыш абынганнар ягына:
Сүнә бары янган учак кына,
Барган кеше генә абына.

Куркасың син кайнар йөрәкләрдән,
Тынмас җаннар җирдә күплектән.
Син бит җирдә, абынудан куркып,
Шуышырга гына күнеккән.

## СӨЙГӘН ЯРЫМ ТЕТТЕ ТЕТМӘМНЕ

Егермешәр яшьлек утыз шофер,
Һәрберебез таза, сөйкемле;
Тик диспетчер Гөлназ миңа гына
Назлап карый иде шикелле.
Гашыйк идем. Әмма Гөлназыма
Сөюемне әйтеп булмады.
Аны миңа Хәйдәр: «Уйнашчы», – дип,
Әшәке сүз белән хурлады.
Кыз намусын яклап, җенем чыкты,
Мыскыл күргәч Хәйдәр күзендә;
Шүрлегенә менеп төшкәнемне
Сизми калдым әле үзем дә.
...Искә килеп, айныгандай булдым
Утырганда хөкем залында.
Зур шикаять итеп язган Хәйдәр
Ачуын да, үпкә-зарын да.
Шаһит – Гөлназ икән. Шушымыни
Мин ашкынып, янып яраткан?
Ул Хәйдәрне сугып екканымны
Күреп торган икән ерактан.
Шул фәрештәм, шушы сөйгән ярым

Тетте генә минем тетмәмне;
Ялварулы назлы карашымны
Игътибарга лаек итмәде.
Җәза таләп итеп яңгырады
Гөлназ таныклыгы бу залда;
Белмәде ул үзе генә сәбәп
Булганлыгын шушы җәнҗалда.
Нәтиҗәсе шундый булды: мине
«Гаепле» дип хөкем иттеләр.
Хәйдәр белән Гөлназ суд залыннан
Култыклашып чыгып киттеләр.
...Сүнмәдем дә, кипмәдем дә әле
Өтермәнең ипи-суыннан.
Кайттым. Хәйдәр – гараж нәчәлниге,
Гөлназ кыскартылып куылган.
Ялгыз яши. Нарасые үсә.
Биргән икән язмыш кирәген!
Минем исә, уйларыма керсә,
Аны теләп әрни йөрәгем.
Түзмәм, ахры, дуслар. Яманлыкка
Мин яхшылык белән түләрмен;
Яннарына барып көләрмен дә
«Әйдә, бергә булыйк», – диярмен.

## «АЛТЫН ҮЗӘН» ФЕСТИВАЛЕНДӘ

Чал тауларны кичеп килдем
Күрер өчен Миассны.
Кәләшләре көләч аның,
Урамнары кояшлы.
«Алтын үзән» очраштырды
Егетләрне, кызларны;
Ялкын икән йөрәкләре,
Матур икән җырлары.
Тәрәзәмнән күренеп тора
Тургаяк күл ярлары;
Алтын үзән аһәңнәрен
Тыңлап туя алмадым.
Гөлнәзирә, Илдар, Фаил,
Галия дә, Әлфия, –
Кардәшләргә-якташларга
Чал Уралым баш ия.
Кем әйткән ул, бетәбез, дип,
Сүнә, диеп, талантлар?
Чәчәк ата гөлләребез,
Ныгып үсә канатлар!

## * * *

*Нил Минәҗевка*

Аерылмаган кебек һич тә
Бер-берсеннән энә-җеп,
Гомер буе гармуныннан
Аерылмый Минәҗев.

Күбрәк үзе сөйкемлеме,

Әллә җыры танышмы?
Әллә Баян Хәсәнычмы,
Әллә Нил Баянычмы?

Өфеләрнең яулыгы да,
Казаннарның сөлгесе…
Якты чырай, татлы курай –
Нил Минәҗев билгесе.

## ТЕЛӘК

Утызынчы еллар җәберләре
Хәтерләрдә – кара бер болыт.
Утыз җиденченең каберләре
Буыннарда калыр шом булып.

Уян, халкым, күтәр чаршауларың,
Сизгер булсын безнең нык сафлар;
Кайтмасыннар бүтән Берияләр,
Тумасыннар бүтән Ежовлар.

Рухи чирләр узган чорда калсын,
Күңелләргә керсен мул сихәт;
Күкләр аяз, һава чиста булсын,
Һәм богаусыз булсын хакыйкать.

## ЧИБӘРКҮЛ

Сәлам сиңа, гүзәл күлләр иле!
Тагын килдем, җаным түзмәде.
Бер серем бар монда, ул серемнең
Саф күлләрдәй зәңгәр күзләре.
Чибәркүл, гүзәл күл,
Вәгъдәләргә тугры була күр.
Әйтче, зинһар, әйтче, күлләр иле,
Узган җәйнең кайда эзләре?
Очрашырбыз, диеп вәгъдә биргән
Сылуымның кайда күзләре?
Чибәркүл, гүзәл күл,
Бергә чакның кадерен белә күр.
Сау бул, күлләр иле! Җилләр исәр,
Җәй артыннан килер көзләре;
Онытылмас ләкин шул сылуның
Саф күлләрдәй зәңгәр күзләре.
Чибәркүл, гүзәл күл,
Вәгъдәләргә тугры була күр.

* * *

*Рәшидә Сиражиевага*

Шундый иде безнең башлык:
Кайный иде татар, башкорт.
Хәзер елга бер сәлам.
Көтмәгәндә Казанына
Китте-барды – вәссәлам!

Күз алдында яшәсә дә,
Без аны күрмәдек шул,
Монда яшәгән чагында,
Кадерен белмәдек шул…

## БҮГЕНГЕ РӘСӘЙ

Юк дилбегә, юк авызлык,
Кылмаганны кыл әйдә!
Йә фәхишлек, йә явызлык,
Юк бүтән юл Рәсәйдә.

## ХИС

Басып бәллүрләрнең балкуларын,
Уктай ярып мәҗлес томанын,
Үзәгемне өзде күз карашың.
Халәтемнең оҗмах сыманын

Кичергәндәй булдым шул минутта,
Гүя татлы төшкә юлыктым.
Актарылды җаным, яндым утта,
Исем-җисемемне оныттым.

Ике ялгыз язмыш тәңгәл килде,
Очраклылык түгел бу һич тә.
Юкса бүтән күзләр күпме иде
Бәйрәм гөрләп торган бу кичтә.

...Бию өермәсе бөтерелә,
Юк-бар зарлар кала үткәндә;
Дөрләп яна дәртем, күкрәгемә
Күкрәкләрең тиеп киткәндә.

Күзләреңә карыйм – күз камаша,
Шул микәнни сөю шаукымы?
Җан эреткеч нәфис челтәр аша
Кулым тоя билең ялкынын.

Изрәп тоям чәчләреңнең исен…
Сизәсеңме тәннәр берлеген?
Без бер асыл хәзер, без бер җисем,
Бүленмәслек бер җан без бүген…

## ЗАЛӘЛ

Убса тавын гизеп төштем дә,
Зәет болынын ерып кичтем дә,
Салкын Чишмә суын, бәхилләшеп,
Күз яшемне кушып эчтем дә,
Карадым да Мәмдәлемә төшкән
Нурларына кичке шәфәкъның,
Ыгы-зыгы, шаулы юлга чыгып,
Кырыена басып шаккаттым.
Бу зур юлдан, зур елгадай булып,
Кайсы – куркып, кайсы – ашкынып,
Кайсы – ялгыз, кайсы – төркемләшеп,

Ага иде кеше ташкыны.
Шушы юлда мин дә зaләл булдым
Тормышымның ямьле язында.
Фани дөнья! Мин дә синең бәндәң,
Мин дә баттым синең сазыңда!
Кем генә юк иде бу агымда:
Ахмак, зирәк, тыйнак, горурлар…
Юаш җаннар эч пошыргыч иде,
Соклaндыра иде кыюлар.
Мавыктырды мине богаусызлар,
Шул дулкынга чумып күмелдем.
Шөбһәсезләр, динсез, тамырсызлар
Җилкендерде минем күңелне.
Шул тәкәббер йөзләр арасында
Төркем шаукымына бирелдем;
Мин үземә-үзем бик зур кебек,
Бик мәһабәт кебек күрендем.
Шатлыкларым, җыйган байлыкларым
Җылыткандай булды канымны.
Ни әрнеде ләкин күкрәгемдә,
Йөрәгемме, әллә җанымны?
Вөҗданнарым сыкрап, хәлдән тайгач,
Саташудан айнып, беркөнне
Янәшәмдә генә күреп алдым
Инсафлылар барган төркемне.
Гомер узган! Ничек күрмәгәнмен
Бер адымда булган пакьлекне?
Шушы мескен байлык байлыкмыни?
Шушы арзан шатлык шатлыкмы?
Ә кайдадыр, таулар артында,
Чикләвекле урман каршында,
Газиз авылым – яшел Мәмдәл бар, ди,
Тәнем шунда ничек кайтсын ла?
Ә кайтмыйча булмый. Салкын Чишмә
Үзәгеннән типкән суларда
Шаулы юлда кунган тузаннардан
Битләремне кирәк юарга.
Җәрәхәтле йөрәгемне тотып…
...Хәзер… шушы юлдан төшәрмен…
Йөгереп, атлап, аксап, үрмәләпме –
Нигеземә кайтып җитәрмен.

## ПЕСИ МАЛАЕ

Өйдән чыккан һәркем борынын уа,
Әрли-әрли Суык Бабайны.
Авыл кибетенең болдырына
Килеп баскан песи малае.
Кышкы кичнең зәһәр салкыныннан
Бүрәнәләр чатный шатырдап.
Нигә чыктың яланаяк килеш,
Ник торасың җилдә калтырап?
Зөһрә апаң арган бугай инде,
Ишегендә эчтән – бастырык;
Ә рәхимле якты тәрәзәсе

Балкып тора сине чакырып.
Карагансың шушы тәрәзәгә,
Нәүмизләнеп, сыкрап, кызыгып;
Эссе бәргән миче каршысында
Утырасы иде кызынып!
Ярар иде яланаякларга
Киштәсенә тезгән башмаклар!
Шунда керсәң, бәлки, Зөһрә апаң
Йоннарыңнан сыйпап кочаклар.
...Ә югыйсә, әйдә, безгә кайтыйк,
Бергә уфтанырбыз кичләрен.
Кил үземә, сикер куеныма,
Минем дә бар яккан мичләрем…

ҖИТӘР!

Бүген кызган усал бәхәсләрдә
Гел бер гади фикер сайлана:
Фәләневне бәреп төшерсәк, ди,
Төгәневне түргә мендерсәк, ди,
Тормышыбыз, имеш, җайлана.
Бүген менә илдә төрле куллар
Төрле якка тарта тәхетне;
Гел тоела безгә: яхшы патша
Бирә, имеш, әзер бәхетне.
Эшләү урынына ду кузгатып
Үлгән түрәләрне сүгәбез;
Әмма никтер артмый байлыгыбыз:
Күлмәк ертык, тишек түбәбез.
Чынлаптамы әллә каныбызга
Мәңгелеккә сеңгән кайгыбыз?
Без кол идек кичә,
Бүген дә кол.
Югарыдан хәер даулыйбыз.
Туганнарым!
Җитәр сукранырга,
Җитәр теләнергә сызланып!
Бәхет өчен үз башыбыз кирәк,
Эшләү кирәк җиңнәр сызганып.

КАЙТСАМ…

Танымастыр Салкын чишмә,
Еллар үткәч тагын кайтсам,
Дөрләмәстер шашып ялкын,
Яр буенда учак яксам,
Җир җылытмас, йолдызларга
Йөзем төбәп җиргә ятсам,
Тәмен тоймам, аланнардан
Пешкән җиләк алып капсам.
Сагынмасмы Зәет-болын
Үзен буйлап үскән улын,
Җырламасмы сайрар кошлар
Мин тыңлаган моңлы җырын,
Баш имәсме өрәңгеләр,

Буйлаганда мәктәп юлын,
Елмаймасмы йөзләр, дуслар
Сузмасмыни миңа кулын?
А! – юк. Таныр туган ягым,
Аермаслар безне еллар,
Елмаерлар ак каеннар,
Алып кайтса шунда юллар;
Елмаерлар дулкын-кырлар,
Урманнардан агар моңнар,
Кочаклашып таллар белән
Бергә җырлар җырларым бар.

* * *

Чыдам безнең рухи нигез,
Һәммәбез дә шат һәм тигез;
Атмасалар – игелек, дип,
Суймасалар – рәхмәт, дибез.

## СИН

Әүвәл балкып төшләремә кердең,
Синме, дидем, әллә түгелме?
Хыялымда туган пакь рәвешең
Иләс итте үсмер күңелне.
Шуннан бирле калды күз алдымда
Чакырулы уйчан күзләрең.
Шул күзләрне Идел ярларында,
Болак буйларында эзләдем;
Уйлар дәрьясында йөрдем йөзеп,
Бәхет теләп акты яшьләрем,
Табылачак хәзинәмне сизеп,
Канатланып, җырлап яшәдем.
...Калын көртләр кинәт эреп акты,
Серле утлар янды офыкта,
Март аенда шомырт чәчәк атты,
Без очрашкан изге минутта.
Шәһәремнең бөек урамнарын
Хыялымда нурга буядым:
Син күрдеңме аны, газиз ярым,
Чынга ашкан якты хыялым?
...Бүген дә шул чәчләр агарса да,
Ел артыннан еллар узышса да,
Безнең хакимебез – чибәрлек.
Мин ышанам, бәгърем, юк дөньяда
Безне аерырлык егәрлек.
Белмим инде, синме минем нурым,
Минме синең учак балкышы?
Син бит минем йөрәгемдә тудың,
Син бит минем җанның яртысы.

* * *

*Рәшидә Идрисовага*

Әй җырлыйсың тыпырдап та,
Җиңнәреңне болгап та.

Әйтерсең лә гашыйк үзең
Гармунчыңа чынлап та.
Ник инженер булып йөрим,
Ник гармунчы түгел мин?
Яннарыңда уйнар идем
Сәхнәләрдә бүген, дим.
Дикъкатеңне тик үземә
Итәр идем мин җәлеп…
...Ник заводта эшләп йөрим,
Еллар буе этләнеп?

* * *

*Рамазан Шәгалиевка*

Ул монда да, тегендә дә, –
Кая гына өлгерми!
Чәчләренә әллә кайчан
Бәс кунса да, сер бирми.
Уйнап-көлеп, җырлап-биеп,
Янып яши шулай ул;
Татар-башкорт үзәгендә
Иң зур башкорт бугай ул.

* * *

Буй-йөз, гакыл безгә болгарлардан килгән,
Дала улы җырыбызга моңнар керткән,
Чыңгыз каны өстәп тәвәккәллек биргән,
Әмма хәмер исе кемнән сеңгән икән?

* * *

*Салисә Гәрәевага*

Монда шыткан милли эшләр –
Аның изге эше ул.
Һәр татарга «Син татар» дип
Тукып торган кеше ул.
Хәзер исә сирәк кенә
Килеп тора хатлары.
...Ул – Уралның Казандагы
Иң мактаулы татары.

## ДОГА

Баш авырта, яна җаным,
Авызда бәдрәф минем.
Бүген дөмекмәсәм, Раббым,
Иртәгә эчмәс идем.
И Ходаем, шәфкатьле бул,
Бар өметем Синдә бит,
Догаларым булсын кабул,
Дүшәмбемне шимбә ит…

## ИПТӘШКӘ

Язмыш безне тигез какты-сукты –
Син дә биртәк, мин дә сакаумын.

Бир кулыңны, иптәш, файдасы юк,
Мәгънәсе юк үпкә саклауның.

* * *

Картлык килде. Ул хөрмәткә лаек.
Кайсы фасылымнан ул ким инде?
«Саумы, картлыгым, – дим, – очраштык бит,
Очрашмавыбыз да мөмкин иде…»

## ЧИЛӘБЕДӘН БӨГЕЛМӘГӘ

Тәрәзәдән карап барам.
Таулар, кырлар, тал-тирәк…
Чиләбедән Бөгелмәгә
Вагон бара келтерәп.
Поезд тизрәк чапкан саен,
Аралар якыная,
Әтием дә көлемсери,
Әнием дә елмая.
Тәгәрмәчләр җырын бүлеп,
Ишетелде бер тавыш:
«Хәзер, дуслар-пассажирлар,
«Җиләк» дигән тукталыш».
Менә вокзал. Тирәсендә
Гөрләп үсә бакчалар.
Учлап җиләк өләшәләр
Юмарт әби-апалар.
Күбәләкләр очып йөри,
Болын тулы җиләклек.
Әйтсәм әйтим, учлап-учлап
Җиләк ашап кинәндек.
Киттек. Янә тәгәрмәчләр
Шакылдавы ешая.
Әтием дә көлемсери,
Әнием дә елмая.
Кинәт тагын матур тавыш:
«Үскәнем, ипләп тыңла!
Тукталышның алдагысы
«Татлы туңдырма» була».
...Нинди генә туңдырма юк:
Төрләре җитмеш җиде;
Җиде яшькә җитеп шуны
Күргәнем һич юк иде.
Җиде төрен авыз иттем,
Җитмеш төре сыймады.
(Әтием дә рөхсәт итте,
Әнием дә тыймады.)
Тагын киттек. Тагын игълан
Шатландырды күңелне.
«Уенчыклар» тукталышы
Тәрәзәдән күренде.
Бигрәк рәхәт булып чыкты
Бөгелмәгә бу барыш,
«Бәлеш» дигән станция,
«Әкиятле» тукталыш.

Саный китсәң, санап була,
Тагын әле әллә ни…
Әнием дә көлемсери,
Әтием дә әрләми.
Һәркайсына төшкән саен
Шатландым да, куандым.
...Әни төртә: «Тор, улым», – ди.
Бөгелмәдә уяндым.
Күрәм: вокзал түбәсендә
Йөнтәс песи мияулый.
Әтием дә ник бер көлсен,
Әнием дә елмаймый.

## ЕЛМАЕГЫЗ, КЫЗЛАР

Елмаегыз, кызлар, елмаегыз!
Боегусыз булсын йөзләрегез.
Күңелләрдә якты яз гөрләсен,
Җиңел булсын баскан эзләрегез!

Елмаегыз, кызлар! Бер елмаю
Боз эретә йөрәк асларында.
Яшәү рәхәт безгә – елмаюлы
Карашларда сезнең яз барында.
Елмаегыз, кызлар…

## ЗАР

Иртән торып, якты таңга карап,
Гүзәллеген күреп дөньяның,
Җырлар идем сиңа Тукай җырын,
Сәйдәш көен, Такташ моңнарын,

Ләкин хәтер… Агуланган хәтер…
Уйларымны баскан ак таплар.
Җырлыйм дисәм, чыга мәдхияләр,
Буш өндәүләр, төссез такмаклар.

Ни булды соң безгә? Улларыбыз
Сайлар икән нинди юлларны?
Әйтче: бүген «Зәңгәр шәл»не укып
Яшен түккән тик бер кыз бармы?

## ҺИЧ СӘБӘПСЕЗ…

Һич сәбәпсез берни булмый, дисең.
Дөрес, ахры.
Тормыш дигән татлы җәфа бигрәк
Төрле яклы.
Кеше кайчак һич сәбәпсез чыга
Тын яланга.
Бәлки, чынлыкта ул сусагандыр
Саф һавага?
Була кайчак: үксеп елый кеше
Һич сәбәпсез.
Көне, димәк, аның ялгыз уза

Һәм рәхәтсез.
...Һич сәбәпсезмени карадым мин
Күзләреңә?
Ирексездән, түз, дип әмер бирдем
Йөрәгемә…
...Һич сәбәпсез берни булмый, дисең.
Дөрес, ахры…

## МӘХӘББӘТ БЕЛДЕРҮ

Мин яратам сезне, көләч язлар,
Мин яратам сезне, шат йөзләр,
Мин яратам сезне, язлы тормыш,
Мин яратам сезне, кешеләр!

## СӨЙКЕМСЕЗ ЯР

Болай булды: җәйге болыннарда
Нәфис гөлләр илен очраттым.
Берсен генә ләкин шул гөлләрнең
Гүзәл яшьлегемә охшаттым.

Алтын көзләр килгәч, гәрәбәдәй
Каеннардан күзем алмадым.
Серләремне түктем күзләреңә –
Берсе генә мине аңлады.

Кышкы озын кичләр тынлыгында
Бик күп моңлы җырлар ятладым.
Онытылды моңнар; ләкин берсен
Йөрәгемдә назлап сакладым.

Мин берәүне генә җырларымда
Сөйгән ярым диеп атадым.
Икәүмени мине тапкан анам,
Икәүмени минем Ватаным?!

Мин берәүгә генә багышладым
Иң кадерле изге хисемне.
Шул хисемнән туган җырларымны
Инде сиңа корбан итимме?

Юк, бирәлмим сиңа җырларымны –
Йөрәгемнең изге өлешен.
Ят йөрәккә бирмим яшьлегемнең
Үз ярына өзгән җимешен.

## УЛ

Зур елгалар суын эчкән,
Бөек диңгез суын кичкән,
Илләр күргән, дөнья гизгән…
Еллар үткән…
Авылының комлы сулы
Буасына кайткан юлы!
Ярга басып башын игән,
Яшен түккән…

## БЕР КЫЗГА

Без һәрвакыт бергә, бер вагонда
Институтка көн дә йөрибез…
Ничек шулай туры килә? Сирәк була
Ялгыз гына йөргән көнебез.

Шыгрым тулы вагон буш шикелле
Син булмасаң әгәр вагонда,
Ышанасым килә – юксынасың
Мин булмасам юлда яныңда.

...Бер кыш узды юлда бергә йөреп,
Бер бинада көн дә булабыз,
Коридорда икәү очрашканда,
Кайчак «саумы» диеп узабыз.

Ни көтәдер язмыш? Тартынамы?
Без үзебез аңа булышыйк,
Бер кыш йөрдек күзләр очраштырып,
Җитәр инде, әйдә танышыйк.

* * *

Бу дөньяда без шыр тиле
Булып гомер итәбез.
Нидер аңлый башлаганда
Гына үлеп китәбез.

## ИМТИХАН АЛДЫННАН

Тагын китап, тагын сопромат.
Тагын менә миңа бу көннең
Көндезенең кичкә авышканы
Тәрәзәдән генә күренде.

Тәрәзәдән генә карап калдым
Бу көнне дә кояш батканын;
Алтын көзнең соңгы аяз көнен
Китап белән бергә «ашадым».

## ЯШЬЛЕК УЗАР

Яшьлек узар. Чәчкә кырау төшер.
Тик йөрәкне кырау капլармы?
Бәлки әле ныграк сагынырбыз
Без иң тиле булган чакларны…

## ЯЗЛАР КИЛЕР

Һәр ел саен ямьле язлар килер,
Сулар гөрләр.
Алтын нурлар күктән сибәләр…
Җиргә кояр көмеш сөңгеләрен
Тунын салып аткан түбәләр.
Без җырлаган яшьлек җырын җырлар
Безнең эне, безнең сеңелләр,

Без яраткан агачларны сыйпап,
Без атлаган юлдан йөрерләр.
Хыялларның кайсы чынга ашар,
Кайсы һаман алда җемелдәр…
Армасыннар иде,
Талмасыннар иде,
Тынмасыннар иде күңелләр!..

## КАЕННАР ЯФРАК ЯРГАНДА

Кайчан гына әле ямьле язның
Юкка чыкты соңгы карлары?
Каеннарның тагын сизми калдым
Кай арада яфрак ярганын.

Шулай икән. Куа елны еллар.
Сулар ага. Хатлар өзелми.
...Бу тормышта кискен борылышлар
Уза кайчак бигрәк сизелми.

Малай идем. Кая очты еллар?
Кайчан уздым тормыш киртәсен?
Бала чагым, алтын балачагым,
Китмә инде, кал беразга тагын,
Нигә шулай иртә китәсең?

Киләчәкнең гүзәл бәхетләре
Әйдәп мине алга илтсәләр,
Якты еллар, сезнең хатирәләр
Йөрәгемне әле иркәләр…

## ШАГЫЙРЬ, ДИЛӘР…

Шагыйрь, диләр, аңлый кеше күңелен, –
Шатлык, хәсрәт, өмет, сагышлар…
Миңа исә булмас шагыйрь булып,
Кеше җаны миңа – табышмак.

Шагыйрь, диләр, аңлый кеше күңелен,
Шагыйрь, диләр – табиб җаннарга;
Мин үземне әле аңлый алмыйм,
Ә читләрне кайдан аңларга?

## ШӘҺӘРДӘ

...Тәрәз аша – кала шау-шуы.
Янда сөйләш – ят та, түгел дә…
Авылым! Кинәт килдең күңелгә
Синнән бигрәк ерак көнемдә.

Кичер, авылым! Ерак калды инде
Арышларның кырда тын шавы.
Кичер! Тартты соңгы мизгелемдә
Пулатларның серле моңнары.

Кемдер әйтә: өздек араны, ди,
Ул җыр безгә түгел кирәк тә…
Арышларым, нишлим? Бүген менә
Сагыш тулды әле йөрәккә…

## ТРАМВАЙДА БАРА ИДЕМ…

Трамвайда берчак бара идем,
(Ахры, Тукай чаты тирәсе.)
Игътибарны кинәт җәлеп итте
Янымдагы парның сөйләше.
Табыштырган язмыш. Пар күгәрчен.
Бер алманың ике кисәге.
Кыз ашыга.
Тынгы бирми егет аның саен,
Танышырга бугай исәбе.
Борылышта кызый төшеп калды,
Бу егет тә. (Сәбәп табылды…)
Порт ягына барган бер вагонга
Кыз утырды.
Егет өлгермәде,
Вагон китте, ишек ябылды.
Сагыш тулы йөзе белән карап
Калды егет чатта, мәйданда.
Аңлыйм сине, егет.
Очратырмы язмыш тагын бер кат?
Трамвайлар
Бигрәк инде күп бит Казанда…
Бәхетләрне утлар-сулар ерып
Табу тиеш, диләр, дөньяда.
Җиңел тапкан бәхет бу тормышта
Бигрәк инде җиңел югала.

## АДАШКАН ЧӘЧӘК

Нигә икән тормыш ташларыннан
Минем йөрәк авыр тырмашты?
Соң татыдым никтер мәхәббәтне,
Соң таныдым олы тормышны.
Мин нарасый идем,
Яшьтәшләрдән
Күпләр инде тормыш корганда;
Мин адашкан чәчәк булып аттым,
Тиңдәшләрем җимеш биргәндә.
Менә таптым сине бу тормышта,
Ләкин тагын – соңга калып мин.
Нәрсә әйтим явыз бу язмышка,
Кемне каргыйм, кемне гаеплим?
Җитәр, язмыш, мине газапларга,
Өр җиләңне хәлсез таҗларга;
Бер адашкан чәчәк һәлакәте
Сабак булыр килер язларга…

## КИТ

Нәрсә әйтим инде? Бер уйласаң,
Сәбәп тә юк болай.
Элек заман булса, әйтер идем
Язмаган, дип, Ходай.
Син бит бөтен гөлләр арасында
Иң гүзәл гөл;
Нигә генә мине сайладың син,
Кем соң мин, кем?
Юк җавабым, сыкраса да җаным,
Син гафу ит.
Без пар түгел бугай синең белән,
Кит гөлем, кит.

ҖЫР

Ул көн бездә бәйрәм булды.
Радиола гел уйнады:
«Син – ялгыз, ә мин – парлы,
Син – ялгыз, ә мин – парлы…»
Отыттыңмы вәгъдәләрне,
Бергәләшеп җырлаганны?
«Син – ялгыз, ә мин – парлы…»
Бүген сагыш күңелем тулы,
Ярсып җырлый Бүл-Бүл углы:
«Син – ялгыз, ә мин – парлы…»
...Мин – ялгыз, ә син – парлы.

АЧЫНУ

Төштәгедәй уза көн арты көн,
Гүзәл еллар! Артта каласыз…
Көн артыннан айны, елны узып,
Җилдәй оча тормыш чанасы…

КЕШЕЛӘР

Кызык кына икән кешеләр:
Ике дөнья белән яшиләр.
Күрсәләр дә юлдан тайпылганны,
Үпкәләтмик, дипме – дәшмиләр.
Эх, кешеләр!
Тормыш көпчәгендә
Саташтырып бутый яздыгыз,
Абындыра язып калдыгыз.

* * *

Үткәннәрдән читен аерылу,
Гүзәл көннәр кала үткәндә…
Ямансулый күңел, риза түгел
Саубуллашу көне җиткәнгә.
Ник шыңшырга, сагыш белән карап
Артта калган матур көннәргә?
Үткән матур булсын якты истәлектә,

Ә омтылыйк һаман гүзәлгә!

## ӘРЕМ

Гүзәл чәчәк эзләп бара идем
Бакчасында гөлле тормышның,
Әллә көлеп, әллә ялгыш кына,
Әрем бирде миңа язмышым.

Нигә миңа әрем, тиңсез гөлләр
Гүзәллеген үбәр чагымда,
Тормышымның сөю белән тулы,
Ләззәт белән тулы чагында?

Күзләремдә яна әле яшьлек,
Ялгызлыктан әле кипмәгән;
Әреме дә ярар иде, диеп
Сыкрар чаклар әле җитмәгән.

## САГЫНУ

Балачагым кире кайтмас инде,
Йөрәк сагынса да кырларын.
Күңел дулый, сагынып шыңшый-шыңшый
Ерак чорның кайтмас моңнарын.

Ун ел элек шыткан хыялларым
Ашмаса да чынга барысы,
Яңа чикле ят хыяллар белән
Йөрәктәге урынын алышты.

Бүген генә кебек уяндым мин,
Бүген генә ачтым күземне.
Ят киләчәк, ят хыяллар белән
Тутырганнар минем күңелне.

Бер киләчәк бирә хакимлеген
Икенченең гөлле таңына…
Бары сыкрый никтер кайчак күңел,
Узган чорны әрнеп сагына.

## БҮГЕНГЕ УЙЛАР

Узар, диләр, яшьлек, тупасланыр
Вакыт томанында күңелләр,
Онытылыр еллар шау-шуында
Язгы яну, көзге көюләр.

Эх, йөрәгем! Нигә ялкыннарың,
Гомер буе дулап янмагач?
Нигә сөю, соң минутка кадәр,
Еллар буе сөя алмагач?

Юк, сүнсеннәр, әнә пыскучылар,
Минем шиңмәс хыял-теләгем.
Чаллар бәсен җиңә алмасмыни
Кайнар хисләр, янар йөрәгем?!

Яңа яшьләр яшьнәп яшәгәндә,
Мин карармын кырын ятыпмы?
Әй, вакытны еллар саныймыни,
Йөрәк саный узган вакытны!

...Узмас, ахры, узмас, ахры, яшьлек.
Тынмас җаным, сүнмәс йөрәгем.
Картайса да тузып сөякләрем,
Яшьлек булыр җирдә терәгем.

## ШИҢГӘН ГӨЛЛӘР ЯНЫНДА

Җилләр исте сыгып агачларны,
Вак яңгырлар дулап яудылар;
Чәчәкләрнең соры сабаклары
Дымлы җиргә елап аудылар.

Көз, көз җиткән…
Гөлләр күптән шиңгән,
Нурлар сүнгән, кояш сүрелгән…

Ә мин, юләр, һаман җәйне көтәм,
Җырлар эзлим йөрәк түреннән.
Ә мин, тиле, гөлле җырлар сайлап,
Чал урманнан, әллә кайлардан,
Үз җырларым белән үзем алдап,
Яз килер, дип өмет яңартам.

## КИСӘТҮ

Ымсынма син «Бигрәк чибәр,
Димәк, затлы хатын» дип.
Чәчәк аткан көннәрендә
Тигәнәк тә матур бит.

## ЯЗЛАР КИТКӘНДӘ

Хисләремнән ташлар җанланырдай,
Бозлар эрер төсле тоелды.
Көлде кояш. Яз кайтмады кире.
Көннәр сүнде, гөлләр коелды.

Нигә миңа язлар? – китсен, китсен, –
Синсез язлар миңа кирәкми;
Бер йомарлам бозга – бер уч йөрәк,
Суытырмын шашкан йөрәкне.

## КАРЛАР

Карлар ява уйнап, бөтерелеп,
Бурап, тузгып, дулап, очынып;
Чәчләремне йолкый салкын җиле
Җитмешенче елның кышының.

Китче, буран, алып еракларга
Сагышларын узган көннәрнең;

Иссен җилләр, күмсен бозлы карлар
Яз китергән яра эзләрен.

Йөрмә, йөрәк, таныш эзләр эзләп,
Бүген буран баскан юллардан;
Бер сүрелгән бәхет – узган ташкын,
Табылмаска инде югалган…
Җитәр. Китим яңа бәхет эзләп
Яңа карлы яңа юллардан.

* * *

Көннәр буе йөзем көләч минем,
«Дусларым, – дим, – җирдә терәгем!»
...Төннәр буе сызлый рәнҗүләрдән
Тишкәләнеп беткән йөрәгем.

## НИГӘ?

Нигә тула хисләр күкрәкләрдә,
Шунда гына янар өченме?
Нигә туа җырлар йөрәкләрдә,
Шунда тынчып калыр өченме?

Нигә гөлләр, сөйгән җаннар өчен,
Дуслар өчен чәчәк атмагач?
Нигә ул кан, йөрәкләрне айкап,
Тамырларда шаулап акмагач?

## ҮКЕНӘБЕЗ...

Үкенәбез сыйпап сыкы чәчне,
Ышанулар узгач юк-барга:
Иртәгәге якты киләчәкне
Кичә кирәк иде дауларга.
Бүген соң шул инде…

## КОЙРЫК

Әмер булса, елгасын да,
Сазлыгын да ердык без.
Йодрык булып кылансак та,
Койрык кына булдык без.

## ДУСЛАР

Телләр аргач, куллар талгач,
Ызгышны ташладылар;
Кулга-куллар тотынышып…
Тибешә башладылар.

## ШАГЫЙРЬЛӘР ҺӘМ ТҮРӘЛӘР

Кемнәр генә менми тәхетләргә!

Тик булса да заман бик мастер,
Шагыйрьләрне түрә итеп була,
Түрәләрдән шагыйрь чыкмастыр.

## ЗУР ҺӘМ НӘНИЛӘР

Үз ишләребезне бу дөньяда
Без дә якламасак, кем яклар?
...Зур ахмакның җылы ышыгында
Үрчеп тора нәни ахмаклар.

## ЯШИМ

Уйларымда «син» дип назласам да,
Очрашканда «сез» дип кыландым.
Җәфаландым икәү очрашканда
Зиһенемне баскан томанның
Әфьюныннан айный алмавыма.
Шимбә җиткәч, бию кичләрен
Көтеп ала идем, тояр өчен
Чәчләреңнең ясмин исләрен,
Билләреңнең серле кайнарлыгын.
Шәрабында йөзеп сихернең,
Вакытлыча килгән бәхетемне
Югалтудан куркып тилмердем.
...Узды еллар. Сагышларга юмарт
Булып чыкты безнең заман да.
Синсез яши алмам, дигән идем,
Шунысы гаҗәп – яшим һаман да.

## МАКСАТЫМ

Ерак язда, кереп барган чакта
Ачып тормышымның капкасын,
Офыгымда таң кояшы булып
Балкып туган иде максатым.

Атлый-атлый тузды башмакларым,
Аякларым сызлап, аксадым;
Чәчкә чаллар керде, тик каршымда
Янып торды изге максатым.

Узды тормыш. Бирмәде шул язмыш
Җылы назын, малын, акчасын.
...Офыгымда таң кояшы булып
Һаман әле яна максатым.

## ФАРАЗ

Үзең дә бит миңа тартыласың!
...Мин дә кыймыйм, син дә базмыйсың.
Күкрәгемә кысып башкаеңны,
Чәчең сыйпап килә назлыйсым,
Куенымда килә иркәлисем,

Бергә көтеп таңнар туасын,
Иләсләнгән кайнар учым белән
Йөрәк тибүеңне тоясым.
Иңнәремә израп сарыласың.
(Фаразларым шундый сизгер лә!)
Сулышымны көтә иреннәрең,
Йөзләр якынлашкан мизгелдә.
Онытыла дөнья, күзләреңнең
Ләззәтеннән күзләр камаша…
Шул минутта кинәт айнып китәм,
Син минеке түгел ләбаса!

* * *

*(Халык җырларына охшатып)*

Кайда, кайда, кайда минем
Каеннарым, талларым?
Егерме ел читтә йөреп
Кайттым – таный алмадым.

Карлыгачлар оя корыр,
Корткыч җәнлек өн казыр.
Торган җирдә каберем калыр,
Туган илдә ни калыр?

Авыл юлын буйлап үсә
Арыш, бодай, борчаклар.
Бер утырып елыйм әле
Арышларын кочаклап.

## КҮРШЕМ

Күршем сәер, таныш-белешләргә
Минем хакта: «Ул бик хәтәр», – ди.
Хуш сүз әйтсәм, кукыраеп йөри,
Тәнкыйтьләсәм: «Ул бит татар», – ди.
Күзгә карап: «Дуслык, туганлык», – ди,
Күрмәгәндә: «Үрчи татар», – ди;
«Татар булган җирдә дөнья тар», – ди,
«Татар исән чакта җир тар», – ди.
Һәлакәткә дучар булып калсам,
Читкә карап: «Батса батар», – ди.
Морадыма җитеп, үсеп китсәм,
«Җирне баса мәлгунь татар», – ди.
Ә мин исә, кырын карашларга
Исем китеп, кырын яталмыйм.
Тормыш сөеп, дөбердәтеп яшим.
Дөрләп яшим, чөнки татар мин.

## «СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР»

Эләктек шул әллә нинди чорга, –
Җирнең гаугаларга бай чагы.
«Соңгы хәбәрләр»не тыңлап уза
Сәгатьләребезнең байтагы.
Ят язмышлар аңны әсир итә,

Фикерләрне урый ят утлар.
Үзебезнең хыялларны чынга
Ашырырга җитми вакытлар.
...Бер моңсу уй уйлап куйдым бүген,
Көзгеләрдә күргәч үземне.
Тормышымның «соңгы хәбәрләре»
Тәмамланып килә түгелме?
Күп татыдым, җитәр, дөньядагы
Җәнҗалларның тозын-борычын.
Бик бирелеп тыңлар вакыт җиткән
Йөрәктәге һава торышын.

## ЯЛА

Гаҗәпләнмим, ничек итеп
Ябышкан, дип, бу яла.
Ялганны күп кабатласаң,
Хак сүз булып тоела.

## ЯВЫЗЛЫК

Явыз булмый, кинә тотмый
Асыл рухлы ир кеше.
Явызлык ул – зәгыйфь тәннәр,
Чирле җаннар билгесе.

## ЯЗ ҺӘМ КӨЗ

Киләчәкнең шатлык-хәсрәтләре
Якты хыялымда язылган.
Якынлашып килгән көзем минем
Кадерлерәк узган язымнан.

## КИЛМЕШӘК

Ят булдым мин җирдә.
Тартты мине
Буш хыяллар, ялган җилкәннәр;
Ярым уңыш, ярым бәхет бирде
Ярым дуслар, ярым сөйгәннәр.
Суык булды тормышымның язы,
Сүрән булды җәйге таңнары;
Аңлаганнар мине яратмады,
Яратканнар – аңлый алмады.
Нәзакәтле булдым, рәнҗерләр, дип,
Нечкә кыллы минем ишеләр.
Әллә кешелекле булганыма
Үз итмәде мине кешеләр?
Сызландыра килмешәклек хисе.
Көн артыннан, пыскып, көн ага.
Әгәр моннан ярты гасыр элек
Килми калган булсам дөньяга,
Ишетмәс тә идем гомер буе
Һәр ахмакның тупас хурлавын,

Һичкемгә дә хәсрәт булмас иде
Бу дөньяда минем булмавым.
...Кинәт килеп керде күкрәгемә
Язгы басуларның саф исе…
Әрни йөрәк, шиңә өметләрем.
...Тик барыбер килә яшисе.

## КАМА

Мәгърур Кама. Гүли су астында
Пароходның авыр калагы.
Әллә су ташкынын, әллә инде
Гасырларны артка кагамы?

Яр буенда, саллар, көймәләрдә
Балыкчылар мыжлый, и бакчы!
Әллә инде зур Каманың үзен
Кармак белән алар тотмакчы?

## ФӘЛСӘФӘ ГЕНӘ

Еллар узган саен бу тормышта
Гел үзгәреп тора һәр бәһа.
Ерак чакта гына куркыныч ул
Әҗәл дигән котсыз аждаһа.

Бер юклыктан бер юклыкка китү –
Һәр адәмне көтә бу әҗер.
Кунак булдым. Рәхмәт хуҗаларга.
Күңелкәем тыныч. Мин әзер.

## ВАКЫТ ЮК

Мәшәкатьле заман. Бер сүзеңне
Ишетәсе иде, ичмаса.
Көн сүрелгәч кенә шатлык калка,
Төннәр җиткәч төннәр очраша.

Юк-бар ыгы-зыгы… Арабызда
Наз-серләребезне кем ташыр?
Җаннарыбыз, күңел күзләребез,
Рухларыбыз кайчан очрашыр?

## ТАБИГАТЬ

Бу дөньяның фани казанына
Бар нәрсәне парлап салганнар.
Һәр ялганда хак сүз тамчысы бар,
Һәр чынлыкта әзрәк ялган бар.

Һәр нәрсәне чама белән бирә,
Табигать ул – кырыс диктатор.
Даның артып, чиксез үсеп китсәң,
Мәтәләчәгеңне көт тә тор…

## ТОТКЫН

Көзгеләргә карыйм – таный алмыйм,
Бумы җанкаемның тирмәсе.
Аның капыл-копыл әмәлләнгән
Җимерелеп барган төрмәсе?

Килеп богауларны өзәр микән
Әҗәл дигән котсыз шүрәле?
...Ни булса да булыр, ә хәзергә
Төрмәсе дә татлы шул әле.

## КӨТҮ

Көзләр елап, язлар дәртләрендә,
Тулып, тагын бушый кесәбез,
Эш саргайта, сөю шатлык бирә,
Ә без һаман бәхет көтәбез.

«Бәхет юк ул, син юләр», – дип шыңшый
Соңгы көзнең соңгы яңгыры.
...Бу дөньяда бәхет көтеп яшәү –
Нәкъ үзе шул бәхеттер, ахры.

## ГАДӘТИ ХӘЛ

Хөрлек җиңде. Явыз патша качты.
Пайтәхеткә кереп урнашты
Халык өчен җанын аямаган
Якты йөзле бөек юлбашчы.

Тик ни хәл бу? Әллә оныттымы
Үзе ирек даулаган чагын?
Буып сүндерергә кереште ул
Һәр кабынган хөрлек учагын.

Шул ук золым, шул ук дуамаллык,
Шул ук мәрхәмәтсез албасты…
Елый халык. Аның катламында
Үсеп килә яңа юлбашчы…

## БИРМИМ…

«Бик пөхтәләп…» – дигән була,
Пөхтәләгән кайда ул!
...Әҗәткә дип биргән китап
Бик таушалып кайта ул.

Китапларны өйдә саклау
Яхшырак дип саныйм мин;
Сорама да, сорамыйм да,
Бирмим дә һәм алмыйм мин.

Зарурлыгын куям аның
Хатын белән бер рәткә.
Хатынны да, китапны да

Бирмим, бирмим әҗәткә.

## ЭЛЕК ҺӘМ БҮГЕН

Юкса төннәр кара иде,
Моңсу иде таңнарда,
Без үлем турында белми
Яшәгән елларда да.

Нигә бүген төн карасы
Йөрәкләрне сызлата?
Нигә бүген таңнар моңы
Уйлата да елата?

Без үлем турында белми
Яшәгән яшь елларда,
Ялкын иде йөрәкләрдә,
Дәрман иде кулларда.

Өмет-хыял тулы иде
Ул таңнарның балкышы;
Утларсыз да якты иде
Төннәрнең караңгысы.

Үткәрәм гомерем көзен
Узганымны кызганып,
Төннәр буе үксеп елап,
Таңнар буе сызланып.

## ТӨШ

Бер төш күрдем: соры томан аша
Шәйлим – бүлмә. Шомлы күләгәм.
Буш өстәлдә ялгыз китап ята,
Кеше кулы күптән тимәгән.

Кулым сузып, шуңа якынлаштым,
Роман микән, шигырь микән бу?
Тузаннарын өреп, тышын ачтым,
Абау, минем гомер икән бу!

## СИН ҺӘМ МИН

Мин заводта тир түккәндә,
Син гел тыпырдап тордың,
Тегесен майлап, бусын җайлап,
Югарыга омтылдың.
Нәтиҗәдә: иш булсак та,
Син – зур түрә, мин – юләр.
Чөнки минем булмады шул
Артымнан этүчеләр.

## БУЛМАСТЫР…

Туып үскән илдә генә
Гомер сөрәсе иде.

Ата-бабалар җирендә
Гүргә керәсе иде.

Гомер узды илне уйлап,
Чит җирләрдә тырмаштым.
Бусы да булып чыкмады,
Тегесе дә булмастыр.

## АЛДАГЫЛАР

Алдагылар, юллар яручылар
Тормышларын илгә бирәләр.
Бар көчләрен сукмак салучылар
Тамчысына кадәр түгәләр.

Морадына җиткәч, җиңүчелек
Шөһрәтеннән ләззәт күрәләр.
...Иң фидакарь алда баручылар
Гадәтенчә яшьли сүнәләр.

## ЧИЛӘБЕМ, УРАЛЫМ

Бу гүзәл дөньяның
Меңләгән юлларын
Әйләнеп-әйләнеп,
Әйләнеп урадым.

Кайларда булмадым!
Тик һаман уйларым
Гел синдә булдылар,
Чиләбем, Уралым,
Чиләбем, Уралым!

Чакырды тауларың,
Зөбәрҗәт урманың,
Фирүзә суларың,
Чиләбем, Уралым!

Бу изге җир ямен
Моңнарда көйләдем,
Җырларда сөйләдем,
Уралым, Чиләбем!

Хәсрәттә – терәгем,
Шатлыкта – бүләгем,
Хыялым, теләгем –
Уралым, Чиләбем!
Уралым, Чиләбем!

## ШИГЫРЬ

Шигырь – җимеш. Пешә йөрәкләрдә
Җан сызлатып, яшьләр түгеп ул.
Өлгерергә тиеш күңелеңдә
Тулган алсу алма кебек ул.
Өлгермәсә – төссез, фикере тар,
Чи алманың кемгә кирәге бар?

* * *

Язлар килсә, дуслар, кайтмам әле
Хатирәләр булып мин сезгә.
Гөлләр ае болай да бит матур,
Язлар көләч булыр минсез дә.
Көзен исә мине сөйгән җаннар
Искә алсын мәҗнүн җырчысын;
Көз сагышын җиңеп, сез дусларны
Мин чыгарган моңлы җыр җыйсын.
...Сагышларда килә юатасым,
Шатлыкларда килми борчыйсым.

## САБАН ТУЕ

Альбомнарда актарынган чакта,
Ирексездән саркый яшьләрем,
Күргән саен рәссам Фәттаховның
«Сабан туе» дигән әсәрен.

Күргән кебек булам сөлге җыю,
Василәнең кара толымын;
Мәмдәл белән Юртыш арасында
Җәйрәп яткан Сыза болынын.

Шул болынга кереп китәр булып
Хәйран калып карап утырам:
Йә көрәшәм мышнап, йә чабышып
Җитез аргамакта сыптырам.

...Ул заманда гармуннардан агып
Дәртләндерә иде саф моңнар,
Ул заманда ирләр аек иде,
Елмаючан иде хатыннар…

## БАРЫБЕР…

Бу дөньяда вөждан кемгә кирәк,
Инсафыңнан үзеңә ни бар?
Урлаганны күреп сөрән салсаң,
Карак белән бергә кыйныйлар.

## ҖӘЙГЕ ЮЛДА

Ике көпчәк чаба җәйге юлдан,
Чикерткәләр булып, әй, сикер!
Артта калып сүнә шомлы уйлар,
Ләззәт биреп туа һәр фикер.
Юкка чыга бөтен сагыш-хәсрәт,
Борчылулар фани юк-барга;
Барган кебек булам «сәпитемдә»
Авылыма, сабый елларга.
«Велосипед» – әй килбәтсез исем,
«Сәпит» җанга бигрәк ятымлы;

«Сәпитем» дип майлап-җайлап торам
Пар көпчәкле җитез атымны.
(Мәктәпләрдә, өлкәннәрне тыңлап,
«Ве-ло-си-пед» диеп этләндек;
«Сәпит» дисәң, зурлар көлә иде:
«Менә мәмдәлләшеп беткәнлек!»
Әй агайлар, аңламадыгызмы
Тел ачкычын, холык чишмәсен?
Мәмдәл авылында туган малай
Мәмдәлләшми инде нишләсен?)
...Пар тәгәрмәч чаба җәйге юлдан,
Саесканны узып оч кына!
...Урал артындагы далалардан
Мәмдәлемә күңел ашкына…

## ХУШ, МАТУРЫМ…

Гаҗәп миңа хәзер ерак язда
Яшь түккәнем салкын мендәргә,
«Бердәнбере түгел икәнмен», – дип
Сызлануым айсыз төннәрдә.
Бүген исә яхшы беләм җирдә
Һәр яздан соң тагын яз барны:
Бүтәннәр дә яратмасынмыни
Мин яраткан чибәр ярларны?
«Хуш, матурым, шат бул, якты юл…
Ятларга да шулай татлы бул».

## СЕРЛӘРЕҢНЕ АЧМА

Бер киңәш бар: ул бәладән саклый,
Гайбәт баткагыннан коткара,
Күңел түрендәге серләреңне
Дусларга да ачма, ятка да.
Бу киңәшне үзем үтәмәдем,
Шуңа хәзер яшим зар ерып.
Ятлар төкереген дусныкыннан
Һич тә булмый икән аерып.

## АЛДЫЙ БЕЛСӘҢ…

Хәйлә белсәң, яшәү җиңел җирдә, –
Беркатлылар сиңа баш исен.
Фаш булмаслык итеп алдый белсәң,
Гадел кеше булып яшисең.

## СЕЗ ҺӘМ МИН

Елау дигән гадәт үтте инде,
Кипте инде корып яшьләрем;
Мин дөньяның бәхетен көтеп түгел,
Хәсрәтенә чыдап яшәдем.

Ә сез, бәхет көтеп яшәгәннәр,

Булмаганны көтеп ардыгыз;
Түземсезлек утларында көеп,
Саргаешып китеп бардыгыз.

Сезне җирдән элек сабырсызлык,
Соңра өметсезлек биздерде;
Ә мин исә яшим бәхет итеп
Йөрәк сызламаган мизгелне.

## И ОНЫКЛАР!

Ничек шытар икән – чүп булыпмы,
Гөл булыпмы безнең орлыклар?
...Бәлки әле минем тормышны да
«Авыр булган», – дияр оныклар.
Ягъни заман мине аямаган,
Йөрәктә чир, кулда сөялләр…
...Бәлки, киресенчә, «Шигырь язып,
Юләр сатып йөргән», – диярләр.
Дөресе шул: ятка ялынмадым,
Шәфкать сорап бер сүз дәшмәдем.
Хәтта өмет җуйган чагымда да,
Мин яшисем килеп яшәдем.
И оныклар!
Иске сурәтемә караганда,
«Яңартабыз», – диеп тимәгез,
Теләсәгез нәрсә лыкылдагыз,
Әмма «Явыз булган» димәгез.

## КАЛГАН БУЛСАМ...

...Бергә булыр идек, калган булсам
Сине тыңлап шулчак әгәр дә…
Мин калмадым туган авылымда,
Син китмәдең шаулы шәһәргә.

Сулып беттем сине уйлый-уйлый,
Саный-саный соры ташларны.
Язмыш микән безне харап итә,
Үзебезнең юләр башлармы?

Хәтеремдә калган рәвешеңне,
Тормышымның таңын сагынам.
Ә син исә бүтән инде хәзер,
Очрашсак та, мине танымассың.
...Хәер, мин дә сине танымам.

## Ә ҮЗЕБЕЗ…

Агымнарга каршы йөзә
Вөҗданлылар һәм кадыйрлар;
Без сокланып кул чабабыз:
«Баһадирлар! Баһадирлар!»
Алар өчен горурланып
Кинәнәбез, кинәнәбез,
Ә үзебез агымнарга

Иярәбез, иярәбез…

## ЧЫГАНАК

Бер җан гына белгән киләчәктә
Минем өчен җырлы чор барын.
Әниемнең бишек җырларыннан
Үрчегәндер минем җырларым.

## ГОМЕР КЫСКА

Әйтер сүзләр бик күп. Гомер кыска.
Көн артыннан, дөрләп, көн ага.
Әйтер сүзне әйтеп бетерергә
Өлгерергә кирәк дөньяда.
Әмма булмый тарих тәҗрибәсен
Инкарь итеп, түксәң дә син яшең,
Яки булсаң да син үтә җор,
Соңгы сүзләр әйтелмичә кала,
Язылмыйча кала соңгы җыр.

## ӘММА

Утын мичтә янып көл булгандай
Бер-бер артлы яна елларым.
Узды гомер. Яшьли хыялланган
Үрләремне яулый алмадым.
Әмма кулым һаман каләм сорый,
Күңелемне тарта җыр тәме,
Бәлки, шушы зәгыйфь касыйдәмнең
Берәр җанга булыр ярдәме…

## ТИЗДӘН, ИМЕШ

«Тиздән тормыш рәтләнер, – ди, –
Сизәсеңме – яз исе?»
...Тиздән, имеш. Минем исә
Бүген килә яшисе!

## ЯШЬЛИ

Яшьли безгә гомер чиксез кебек,
Мәңге кебек туган оябыз.
Яшьли үзебезне картлыктан да,
Вакыттан да өстен тоябыз.

## ЧЫРШЫ ЯЗМЫШЫ

Чыршы язмышы –
Кеше язмышы:
Башта назлыйлар,
Җырлап данлыйлар,
Бәйрәмнәр үткәч,
Кирәге беткәч,
Тышка чыгарып
Чүпкә ташлыйлар.

## ИКЕ АВАЗ

Истә генә калды кояшлы яз,
Һаваларда – кошлар кыйгачы.
...Без аерым чакта – ике ялгыз аваз,
Бергә чакта – моңлы көй башы.

## КӨЗГЕ КИЧТӘ

Көзге кичтә, туплап зарларымны,
Түземнәрем беткәч җил тыңлап,
Саргаеплар беткән хатларыңны
Кабат-кабат укыйм йотымлап.

## КӨЗГЕ КАРШЫНДА

Үз-үзеңне көзгеләрдә күреп,
Хәсрәтеңнән әрнеп көясең.
Шунда карап, үз-үзеңне күрми,
Ни күрергә иде ниятең?

## МАВЫКСАҢ…

Узган заманнарны әрли-әрли
Күрми калмыйсыңмы бүгенне?
Еш борылып артка карый-карый
Мәтәлүең мөмкин түгелме?

## МИЗГЕЛ

Нәтиҗәсе нидә, сәбәпләре,
Кичә микән хәзер, бүгенме?
Изүеңнең алтын сәдәпләре
Чишелергә тора түгелме?
Ялкын ялый кебек битләремне,
Чир тигәнме әллә үземә?
Күзләреңдә укыйм хисләреңне.
Чиш төймәңне. Кара күземә.
Тезләр белән тезләр очрашканда,
Күкрәк белән күкрәк тоташканда,
Йөрәк белән йөрәк кавышканда…

## ГАЛӘМӘТ

Кырыс холык, аз сүзлелек
Гаделләргә хас була;
Артык төче телле кеше
Ялганга һәвәс була.

## БӘЛА

Сүзләр, сүзләр… Йөрәгеңне тишкән

Бәхетсезлек дигән кара ук.
Нишлим инде? Сине юатырга
Сүзләремнән бүтән чарам юк.

## ГӨНАҺСЫЗ ХАТЫН

Хыянәтчел булды сөйгән ярың,
Тик сереңне читкә чишмәдең.
Тапталудан өзгәләнде җаның,
Тик яшәүчән икән хисләрең.

Мәхәббәтең – җәйге үлән синең.
Чалгы узган эзгә, әй, кара.
Янә үсеп чыга чапкан саен,
Таптасаң да, кабат яңара.

## ЯЗМЫШЛАР

Затсыз булып туган – затсыз яши,
Холкы мескен булган – гел байгыш.
Җәен сокландырган чәчәкләрнең
Шиңү көннәре дә соклангыч.

## ТУКТАМАГЫЗ

Атлаучылар, баручылар, туктамагыз,
Арсагыз да, талсагыз да гел барыгыз!
Ярты мизгелгә булса да туктасагыз,
Буйсынмаслар кабат аяк-кулларыгыз.

## КАРТЛЫК

Кисеп бетерелгән урмандагы
Исән калган ике агач без.
Бер-беребез белән куаныштык,
Бу дөньяда ялгыз калгач без.

## ТОРМЫШ МӘГЪНӘСЕ

Сату-алу, исәп-хисап,
Дан, кәнәфи, мал-милек…
Син яшисең бу дөньяда
Мәңгегә килгән кебек.

Яшәү мәгънәсе – шул, диеп
Юатасың үзеңне.
Әмма, дускай, киңрәк итеп
Ачып кара күзеңне.

Гомер – кыска, дөнья – фани,
Егыла гөлләр, сулып.
Тормыш узар, тәннәр тузар,
Мөлкәт очар көл булып.

Унбиш елдан онытылыр
Эшең, даның, кадерең,
Утыз елдан, тигезләнеп,
Юкка чыгар каберең.

Минем исә мәхәббәт һәм
Сафлык – җаным кәгъбәсе;
Шунда гына тормыш яме,
Шунда гына мәгънәсе.

## ОНЫГЫМА

Җырлар нәселләрне тоташтыра,
Буыннарга, диләр, юл сала.
Шуңа күрә өметләнәм, исәр,
Бәлки, йөрәгеңә барып җитәр
Ун шигырем генә булса да.

## КАРТ

Әллә нинди чир тәнемдә,
Максат та юк, теләк тә.
Тизлек тә юк эшләремдә,
Куәт тә юк беләктә.

## ГАЗАП

Гөнаһсызлар чери зинданнарда,
Каннар ага, җаннар кыела...
Шунсы газап: шушы кан коюда
Мин гаепле кебек тоела.

* * *

Тел шартлатып алдашабыз,
Көязләрне матур, дип,
Тыйнакларны куркак, диеп,
Оятсызны батыр, дип.

Ни эшләрбез, җирне, үрчеп,
Риялылар тутыргач,
Чын матурлар, чын тыйнаклар,
Чын батырлар юк булгач?

* * *

Балам тинтәк, балам юньсез, дисең –
Саесканнан былбыл тумый шул.
Нишләсәң дә, кәкре бagананың
Күләгәсе туры булмый шул.

## КОНЦЕРТТА

Без ашкынып килгән идек бер сөйкемле җыр көтеп,
Нигә болай каркылдыйсың, козгыннарны өркетеп?

## ТӨП ХАКЫЙКАТЬ

Дошман белән дустым бергә
Агарттылар чәчемне;
Хәсрәттән дә, мәзәктән дә
Байтак түктем яшемне.

Әмма тишә алмаган күк
Хәйлә каты токымны,
Хыянәт тә, мәхәббәт тә
Үзгәртмәде рухымны.

Тора-бара төп хакыйкать
Аңлашылды миңа да:
Иң кыйммәтле зиннәт – сөю
Һәм сөелү дөньяда!

Дөнья татып шушы чаклы,
Сокланырга хакым бар.
Кырык биштә бигрәк татлы
Була икән хатыннар!

## ДИВАНА

Төшләремдә уттай тәннәреңнең
Һәр карышын үбеп шатланам.
Тойгыларым шашып, ярсып үксеп,
Кайнар күкрәгеңә капланам.

Син чагылып киткән аргы якка
Йөзгән кебек булам су ярып.
Иреннәрең тәмен иренемдә
Сизгән кебек булам, уянып.

Әй дивана! Яшәмәкче булам
Бутап кичә белән бүгенне.
Яратылып һәм яратып йөрер
Заманнарым узган түгелме?

* * *

Ачуланма, үпкәләмә миңа,
Җинаятьче түгел, корбан мин;
Сөйгән ярын йолып алам, диеп,
Сазда һәлак булган җанга тиң.

Гаҗәпләнмә, куркаклыктан түгел,
Җәрәхәтем әрнеп егылдым,
Мин үрмәләп узып барам бүген
Соңгы аршыннарын юлымның.

Гаепләмә, холкың тупас, диеп,
Ничек түзим, – шома йөзлеләр,
Газиз халкым билен бөккән чакта,
Аны талап, майда йөзделәр.

Үгетләмә мине, ышан, диеп,
Якты киләчәккә, шатланып.
Ничә тапкыр, таңнар көткән мәлдә,

Шәфәгымны болыт каплады.

Шелтәләмә, син Алласыз, диеп,
Зәгыйфь икән, диеп, иманың:
Кырык елым динсез илдә үткәч,
Кемгә инде бүген ышаныйм?

Дан куасың, димә, фани җирдә
Дуслар гына булды терәгем;
Шаулы шөһрәт мине кызыктырмый,
Тик бер генә минем теләгем:

Мине белгән, мине сөйгән дуслар
Каберемә башын иселннәр,
Тик, уфтанып, мескен, димәсеннәр,
Ә вөҗданлы булган, дисеннәр.

## ХАТ

*«Бездең, ахры…»*

Үпкәлисең миңа, шелтәлисең,
Үпкәләргә, дөрес, хакың бар.
Көннәремнең бигрәк күбен били
Рәсми дуслар, салкын хатыннар.

Төшләремдә Мәмдәлләрдә йөрим
Синең белән төннәр буена;
Җитди киңәшмәләр уртасында
Чуалтасың кереп уема.

Җиңел булыр иде бер авылның
Ас башына төшү үр баштан,
Тик бу ике кала бер-береннән
Бигрәк инде ерак урнашкан.

Бизү мөмкинмени, язмышкайлар
Толымнардай бергә үрелгәч!
Җирләр тетрәп, күкләр ишелсә дә,
Безнең җепләр инде өзелмәс!

## «ДУСЛЫК»

Яңа елның шаян буранында
Көрткә чумды дала юллары…
Татарларга газет бүләк итте
Туксанынчы елның гыйнвары.

Яктыргандай булды шулчак офык,
Таралгандай булды томаннар,
Шул газетның тәүге саны кебек
Балкып туды матур хыяллар.

Имеш, «Дуслык» бизәр дөньябызның
Һәр иртәсен, көнен, кичен дә,
Айбулатов Шиһаб дигән исем
Һәр татарның калыр исендә.

Әмма соңра, йә дөрләде ярсып,
Йә пыскыды милләт учагы,
Сикәлтәле булды юлларыбыз,

Авыр булды газет сукмагы.

«Дуслыгы»быз, кайда син? Түрәләр
Тәхет яулап мәш килә, ә без:
«Менә хәзер… Хәзер туа…» – диеп,
Иләсләнеп газет көтәбез.

Көн дә газет көтә йөрәккәем,
Тартылгандай җаным кыйблага…
Яшәсен лә, яшәсен лә «Дуслык»,
Өр-яңадан туып дөньяга!

## ЗАР

Кичә генә якты иде язмыш,
Бүген дәртем кая таралды?
Әллә нинди куе кара сагыш
Күкрәгемә килеп кадалды.

Байтак эчтем вөҗдан газапларын,
Калган икән әле тагынмы?
Үткәндәге хата-гөнаһларым
Дәррәү кайтып телә җанымны.

Вакыт күмсә дә шул яшь чорымның
Яхшылыгын яки зарарын,
Гомер буе тоям вөҗданымның
Мәрхәмәтсез хөкем карарын.

Яшьлегемнең өмет-хыялына
Күптән инде узды җеназа...
Үзем әле яшәгәндәй булам.
Күпме дәвам итәр бу җәза?

## ӨЗЕЛГӘН ӨМЕТЛӘР

*Мәрхүм әтиемә багышлыйм*

1

Әй саташам бугай…Кайда соң мин?
Уңда авылым. Чишмә чылтырый.
Сулда көзге кояш нурларында
Кызгылт сары урман ялтырый.
Ялкылдавы зәһәр ...Әллә янгын
Чорнап алган каен урманын?
Әллә яна минем хатирәләр,
Ялкынсынган фикер-уйларым?
Чү! Менә шул ялкын уртасында
(Абау, әрни хәтер ярасы!..)
Күренеп киткән кебек булды миңа
Әтиемнең моңсу карашы.
Аһ, әтием!.. Өнме, төшме соң бу?
...Кайнар маңгаемны ут ялый…
Беләм бит мин , кабереңне бүген
Миләш яфраклары сыйпалый.
Әти, әти! Китмә, китмә инде!
Ябылмасын уйчан күзләрең!
Күкрәгемне ертып, кайнап тора

Әйтелмичә калган сүзләрем.
Белсәң иде, әти, бу йөрәгем
Күпме сөеп, күпме бизәнде;
Гөрләп чәчәк аткан өметләрем
Ничә тапкыр шартлап өзелде…

2

Хатирәләр мине эзәрлекли,
Ерак узганнарны кузгата;
Өй артында үскән бөдрә каен
Төшләремә кереп елата.
Без – сабыйлар белән бергә уйнап,
Иркәләнеп безнең назларга,
Яшел шәлле сеңлем җырлап үсте
Шаян җырын гөлле язларда.
Мин хәтерлим, әти, син авырдың,
Тәкъдиребез сызды зар көен;
«Бу сырхаудан дарулар юк», – диеп,
Сыкрап яшен түкте әнием.
Күрше Гыйльми апа киңәш бирде:
«Дәвалауны шуннан башлагыз:
Каеныгыз – хәсрәт агачы ул,
Аны тизрәк кисеп ташлагыз!»
...Каенны һәм сине кызганудан
Ярсып көйдем гүя мин утта;
«Ник елыйсың, улым?» – дип сорадың,
Каен һәлак булган минутта.
Син үзеңне-үзең алдадыңмы,
Әллә язмыш сине алдады?
«Зар агачын» кисеп ташлау белән
Сырхавыңны Ходай алмады.
Ерак язда каен шаулавына
Кушылып җырлар җырым бар иде.
Әти! Каен – зар агачы булса,
Димәк, Рәсәй – тоташ зар иле?
Елак малай! Алдар әле сине
Якын дус та, назлы кочак та.
Киләчәгең – югалтулар чоры.
...Кем белгән бит аны шул чакта?..

3

Дөнья тәмен татып чәч агарттык
Без – авылдан качкан егетләр.
«Туган авыл – яшел бишек», – диеп
Әйдәп торды безне өметләр.
Кайтыйм әле, кайтыйм авылыма,
Гөлле болыннарда йөрермен,
Егерме ел мине көтеп яткан
Зәңгәр күлләремне күрермен.
Кайтыйм әле гүзәл әкияткә,
Кошлар сайрый анда тал-тирәктә;
Саф йөрәкле матур кешеләр,
Уңдырышлы табигатьне мактап,
Хезмәт сөеп анда яшиләр.

Кайттым…
Гүя кемдер бетерергә
Ниятләгән явыз дошманны,
Күрмәдем мин ямьле болыннарны,
Ишетмәдем сайрар кошларны.
Чәчәкләрем агуланып шиңгән,
Чиста күлләр кибеп корыган;
Җил искәндә үле тузан оча
Якындагы арыш кырыннан.
Гөнаһларын кая куярмын, дим,
Бергә уйнап үскән Алмазның
Аракы һәм сагыш сәбәбеннән
Сулган йөзен таный алмадым.
Күпме йортлар монда бушап калган!
Сипми авылым кичке утларын.
Кала сәүдәгәре дача иткән
Күрше Гыйльми апа утарын.
Җимерелде изге хыяллары
Ят җирләрдә узган елларның.
...Сирәк үскән зәгыйфь арышларын
Күкрәгемә кысып еладым…

4

Төнге мәйдан кинәт пәйда булды.
(Чуалышты бугай уйларым.)
Күзләремне камаштырып балкый
Өстә янган йолдыз нурлары.
Нәрсә соң бу? Үзе ифрат якты,
Үзе салкын гүя гүр бозы…
Ә, таныдым аны! Якут йолдыз –
Иманымның бөек йолдызы!
Янәшәмдә төркем-төркем йөзләр,
Төрле төсле төрле халыклар:
Күзләрендә – ихлас бирелгәнлек,
Телләрендә – татлы данлыклау;
Һәммәсе дә дәртле җырлар җырлый,
Һәркайсы да нурга баш ия;
Ал байраклар шунда җилфердиләр,
Зур сурәтләр, алкыш, мәдхия…
Шул йолдыздан, шушы ал нурлардан
Дөрләп китеп, мин дә кабындым…
Әти! Бүген генә уяндым мин,
Ялганнардан айнып арындым!
Кайда булган кичә бу хакыйкать,
Кем иҗаты икән бу хата?
Әйләнәмдә – комсызлык һәм фәхеш,
Монафикълык, черү, сафсата!..
Инануым илһамлыгы белән
Күпме гөнаһ җирдә кылынган!
Җәһәннәмгә килеп чыктым кебек
Барган чакта җәннәт юлыннан.
Кичә дошман булган кешеләрне
Бүген күккә чөеп мактыйлар;
Явыз җинаятьче булып чыкты

Без сокланып үскән даһилар.
Яшьтән укып үскән, әкиятләр,
Сез саргаеп дөнья куйдыгыз!
Идеалларым, якты хыялларым,
Татлы төшләр, бәхил булыгыз!
Шушы хәрабәләр уртасында
Газиз хисләремне югалттым.
Яңа юлны башлый алырмынмы?
Төзәлерме сынган канатым?

5

...Күзләремне ачтым, һәйкәлләрнең
Шыксыз өемнәре артыннан,
Мине чакырып, өмет кояшының
Мәңге сүнмәс нуры балкыган.
Яраларым әрнеп сыкраса да,
Таң төсенә күгем буялды;
Ышанасым килде киләчәккә,
Яңартасым килде хыялны.
Тормыш дәвам итә. Басылдылар
Үпкә-гарьләр, хәсрәт-кайгылар;
Яңа теләкләрем, көл астыннан
Шытып чыгып, яфрак ярдылар.
Көзнең салкын томаннары аша
Мин ашкынып тоям яз исен;
Киләчәкне уйлап, хыялланып,
Их, яшисем килә, яшисем!
Рәхмәт сиңа, әтием, үстергәнсең
Көр күңелле итеп улыңны;
Ләкин яңа авыр фаҗигаләр
Киртәләмәс микән юлымны?
Елмайсыннар иде кардәшләрем,
Тынсын нәфрәт, кипсен күз яшьләре,
Гөрләп үссен арыш-бодаем!
Үкенмәскә, кабат җимермәскә
Насыйп булсын иде, Ходаем!..

ЭЧТӘЛЕК

Мәдхия
Без
Җәйләр аша, кышлар аша...
Шатланырга теләү
Әтием кабере янында
Улыма
Кайтып барам
Гомерем
Гаяз Исхакыйны укыганда
Җәлил сурәте
Мәтрүшкәле чәй
Туфан
Күрше малае
Сабан туе таңнары
«Күрсәтте лә дөнья миңа күрмәгәнне...»
Кайту
Бик еракта...
Казанда кунакта
Килеп күкрәгемә сыенсаң
Ике җәза
Көз
Кышкы тамчы
«Үзгәрмәгән, ахры, җисемем минем...»
Гөләп
Тайгада
Көз башы
Үпкәләшкәч
Алиһәм
Яз
Көнләшүем – сөюдән
Кайда булды уйларың?
Озату
Манзара
Ташкын
«Ташкыннар да кичтем...»
Дуска
Бабай хикәясе
Яз нурында тапкан...
Көз
Хыяллар
Минем исә...
Яшим
Аерылышу
Сорамагыз...
«Миәсләргә төшәбез дә...»
«Баер өчен яшисеңме...» ..
Юләр такмаклар
«Аһ, син, мескен адәм балакае...»
Гомер
«Сибелә чәчәк, сибелә чәчәк...»
Көз
Белеп торган идек
«Алга, диләр, алга, диләр...»
«Юк, картаймыйм...»

«Өметләрем шытып сулды...»
Үз күрделәр
Кичерденме икән?
Сурәт
Соңарган мәхәббәт
Сарыкүл
Хатлар көтәм
Язгы урам
Аҗаганнар
Кеше
Көмеш туй
Шагыйрь һәм шигърият
Ике чибәргә мәдхия
Яшәп йөргән булдык
Ярың керсә ятлар кочагына...
Елмаешыйк
Уй
Киңәш
Сөйгән ярым тетте тетмәмне
«Алтын үзән» фестивалендә
«Аерылмаган кебек һич тә...»
Теләк
Чибәркүл
«Шундый иде безнең башлык...»
Бүгенге Рәсәй
Хис
Заләл
Песи малае
Җитәр!
Кайтсам...
«Чыдам безнең рухи нигез...»
Син
«Әй җырлыйсың тыпырдап та...»
«Ул монда да, тегендә дә...»
«Буй-йөз, гакыл безгә болгарлардан килгән...»
«Монда шыткан милли эшләр...»
Дога
Иптәшкә
«Картлык килде...»
Чиләбедән Бөгелмәгә
Елмаегыз, кызлар
Зар
Һич сәбәпсез...
Мәхәббәт белдерү
Сөйкемсез яр
Ул
Бер кызга
«Бу дөньяда без шыр тиле...»
Имтихан алдыннан
Яшьлек узар
Язлар килер
Каеннар яфрак ярганда
Шагыйрь, диләр...
Шәһәрдә
Трамвайда бара идем...
Адашкан чәчәк

Кит
Җыр
Ачыну
Кешеләр
«Үткәннәрдән читен аерылу...»
Әрем
Сагыну
Бүгенге уйлар
Шиңгән гөлләр янында
Кисәтү
Язлар киткәндә
Карлар
«Көннәр буе йөзем көләч минем...»
Нигә?
Үкенәбез...
Койрык
Дуслар
Шагыйрьләр һәм түрәләр
Зур һәм нәниләр
Яшим
Максатым
Фараз
«Кайда, кайда, кайда минем...»
Күршем
«Соңгы хәбәрләр»
Яла
Явызлык
Яз һәм көз
Килмешәк
Кама
Фәлсәфә генә
Вакыт юк
Табигать
Тоткын
Көтү
Гадәти хәл
Бирмим...
Элек һәм бүген
Төш
Син һәм мин
Булмастыр...
Алдагылар
Чиләбем, Уралым
Шигырь
«Язлар килсә, дуслар, кайтмам әле...»
Сабан туе
Барыбер...
Җәйге юлда
Хуш, матурым...
Серләреңне ачма
Алдый белсәң...
Сез һәм мин
И оныклар!
Калган булсам...
Ә үзебез...
Чыганак

Гомер кыска
Әмма
Тиздән, имеш
Яшьли
Чыршы язмышы
Ике аваз
Күзге кичтә
Күзге каршында
Мавыксаң...
Мизгел
Галәмәт
Бәла
Гөнаһсыз хатын
Язмышлар
Туктамагыз
Картлык
Тормыш мәгънәсе
Оныгыма
Карт
Газап
«Тел шартлатып алдашабыз...»
«Балам тинтәк, балам юньсез, дисең...»
Концертта
Төп хакыйкать
Дивана
«Ачуланма, үпкәләмә миңа...»
Хат
«Дуслык»
Зар
Өзелгән өметләр

Литературно-художественное издание

Сабиров Ирек Нагимович

ПЕЙЗАЖ

Стихи

(на татарском языке)

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Рәссамы *М.А.Җиһаншина*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректоры *Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшрияткa 04184 номерлы лицензия 2001 елның
6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.04.2004.
Форматы 70Х90 1/32. Шартлы-басма табагы 4,10+форз.0,15. Тиражы 1000. Заказ Э-309.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/
E-mail: tki@books.kazan.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.